Рафис Гыйззәтуллин

КӨТЕЛМӘГӘН СОРАУ



Рафис Гыйззәтуллин

КӨТЕЛМӘГӘН СОРАУ

Хикәяләр

Казан
Татарстан китап нәшрияты
1990

ББК 84(2Р—Тат)-4
Г 92

Л. ЗОЛОНДИНОВА рәсемнәре

КЕЧЕ ЯШЬТӘГЕ МӘКТӘП БАЛАЛАРЫ ӨЧЕН

ISBN 5—298—00475—X

© Рафис Гыйззәтуллин, 1990
© Л. Золондинова, рәссам, 1990

КАЙНАР ДӘФТӘР

ТЫЛСЫМЛЫ СҮЗ

Уйларыма бирелеп атлый торгач, урам чатына килеп җиткәнмен икән. Каршы якка үтәргә теләп, тирә-юнемә каранып торганда, урам аша чыгып килүче кечкенә буйлы малай белән әбине күреп, ирексездән тукталып калдым.

Малайның бер кулында төенчек, икенчесе белән әбине җитәкләгән. Әбекәй әледән-әле карана. Күрәсең, машина-фәлән бәрдереп китмәгәе дип борчыла. Малайның йөзе тыныч, чөнки ул-бу булмасын яхшы белә: урам чатындагы светофорның яшел күзе чекерәеп янып тора.

Ниһаять, малай белән әби мин басып торган урынга чыгып җиттеләр. Зур төенчек әби кулына күчте. Карчыкның шатлыгы йөзенә үк бәреп чыккан.

— Рәхмәт, улым. Кул-аягың сызлаусыз булсын,— дия-дия ул кечкенә юлчының аркасыннан сөйде.— Рәхмәт яусын үзеңә.

Малай да бәхетле елмая. Аның куанычына сөенгәндәй, муенындагы кызыл галстугы да талпынаталпына җилдә уйнаклый. Әнә малай саубуллашты да, әбигә хәерле юл теләп, ары китте.

Әлеге гадәти, көн саен очрап торучы күренеш миңа күптән булган бер вакыйганы хәтергә төшерде.

...Ул чакта миңа да шушы малай кебек ун-унбер яшьләр булгандыр. Ашыга-кабалана мәктәптән кайтып барышым. Ашыгуымның сәбәбе шул: телевизордан маҗаралы кино күрсәтәләр. Менә кайтып җи-

тәргә дә күп калмады инде. Шул чак мине бер абый туктатты.

— Энем, Батырлар урамына ничек барырга икән?

— Ул монда түгел бит. Сезгә икенче якка барырга кирәк.

Таныш түгел абый, аптырап, башын чайкады.

— Мине әле генә шушы тирәдә дип җибәргәннәр иде бит.

— Юк, юк, теге якта ул Батырлар урамы.

Инде кемгә ышанырга, дигәндәй карый агайның күзләре.

— Әйдәгез озатып куйыйм алайса,— дидем мин. Юлда барганда абый үзенең ерактан килүен, безнең калада әле беренче тапкыр гына булуын әйтте. Сөйләшә-сөйләшә, Батырлар урамына килеп чыкканыбызны сизми дә калдык.

— Рәхмәт, энем,— диде абый, эзләп-эзләп тә таба алмаган урамда басып тору шатлыгын яшерә алмыйча.— Зур рәхмәт сиңа!

Ул чакта маҗаралы кинону карарга соңардым соңаруын. Әмма мин моңа бер дә борчылмадым. Аннан соң да бик күп кинолар карадым. Күбесе инде хәтердән дә чыккан. Тик таныш булмаган абыйга юл күрсәтүем, аннан ишеткән рәхмәт сүзе, шатлыктан елмайган йөзе әле дә истә, хәтердә саклана. Тылсымлы сүздер ул рәхмәт сүзе, дип уйлап калдым мин кызыл галстуклы, кечкенә буйлы малай артыннан.

СОҢАРУ

...Укытучы Сәрия апалары ул көнне, ни сәбәптәндер, мәктәпкә килмәде. Шуңа күрә җиденчеләрнең соңгы дәресләре булмады. Ә дәрестән соң Илбулатларга район үзәгеннән килгән вәкил белән сугыш һәм хезмәт ветераны Зиннур абыйлары комсомол

билеты тапшырырга тиеш иде. Соңгы дәрес булмагач, көтәргә байтак вакыт бар иде әле. Илбулатның классташлары шау-гөр килеп өй эшләре әзерләргә керештеләр, ә ул класс җитәкчеләре янына килде.

— Хәмидә апа, әни авырып тора... Кайтып эшләрне караштырып килим әле.

— Өлгерерсеңме соң? Кунаклар килергә тиеш бит,— диде Хәмидә апасы.

— Өлгерәм,— дияргә ашыкты малай,— мин чаңгы белән...

Аларның өе авыл башында ук. Мәктәп белән ике ара чакрымга якын. Чапты гына Илбулат. Маңгаен яулык белән кысып куйган әнисе улын күргәч куанып китте.

— Әнием, бүген безгә комсомол билеты тапшыралар,— диде малай шатлыгын яшерә алмыйча.

Ашарга зарыгып көткән малларга хуш исле печән салып керде ул. Йөгерә-йөгерә дигәндәй су китерде.

— Улым, өлгерсәң, Мәрьям апаңнан дару гына алып чыгып бирче,— диде әнисе йөрәк турысын угалап.

Өлгермиме соң! Анысына да өлгерде Илбулат.

— Юлың уңсын, улым,— дип озатты аны әнисе.

Ярты араны узгач, малайны ак карга уралган хат ташучы Сания апа туктатты.

— Энем, зинһар, менә бу хатны Гыйльфан абыйларыңа гына илтеп бирче,— диде хат ташучы апа.— Ашыгыч ул. Кызлары авыр хәлдә икән. Шәһәргә баручы поездга өлгерергә кирәк аларга...

Илбулат чаңгыларын кирегә борды.

...Телеграмманы тапшырып чыкканда тантана башланырга санаулы минутлар гына калып бара иде инде.

— Юк, соңарырга ярамый. Комсомол билетын ип-

тәшләр белән бер сафта торып алырга тиеш мин,— дип уйлады малай. Әлеге уй аңа көч биргәндәй булды, адымнары ешая төште. Алда, ниһаять, мәктәп бинасы күренде. Менә ул мәктәп ишегалдында. Коридор. Ленин бүлмәсе янына җиткәч, Илбулат капыл гына тукталып калды. Эчтә кемдер дулкынланып сөйли иде.

— Соңардым! Сүземдә тора алмадым! — дип үзен тиргәде малай. Ә эчке бер тавыш аны аклый иде: «Син шар сугып йөрмәдең. Син игелек эшләдең. Кер, оялма...»

Һәм Илбулат, булган бөтен кыюлыгын җыеп, Ленин бүлмәсенең ишеген ачты...

ЯЛГЫЗ КЫЗ

Инде менә ничә көн укырга йөрми, мәктәпкә бара алмый Гөлнара. Авырып аяктан егылды да урын өстендә ята. Ярый әле врач апалары гел килеп-китеп йөриләр. Укол кадагач, алар калдырган даруларны эчкәч кызга бераз хәл кергәндәй була: башы авырту кими төшә, күз аллары яктырып киткәндәй тоела.

Гөлнара мәктәпкә бара алмаса да гадәте буенча бер үк вакытта йокыдан уяна, күзләрен ача. Әтисеннән караватын тәрәзә янына ук күчереп куюын сораган иде. Укырга барыр вакыт җитте исә мендәрен җайлап куя да тәрәзәгә каплана. Өченче каттан аска карасаң, бөтен урам уч төбендәгедәй күренә. Эшкә ашыгучы абый-апалар да, классташлар да...

Бүген дә шулай булды. Әнисе куйган тәмле ризыклардан авыз итте дә, тәрәзәгә сарылды кыз. Тыштагы хәрәкәтне күзәтергә кереште.

Тиздән, биш катлы йорт почмагыннан Сәлимә күренәчәк. Гөлнара белә: классташы һәркемнән алдарак килә мәктәпкә. Чыннан да шулай булды. Өстенә кыска тун кигән, муенына озын шарф ураган Сәлимә ашыга-кабалана мәктәп ягына атлады.

«Классның иң яхшы укучысы шул,— дип көнләшеп карап калды аның артыннан Гөлнара.— Бүген дә «биш»ләрне күбрәк алырга ашыга әнә».

Сәлимә күздән югалуга күрше йорттан Газим белән Вәзимнең чыгып килүе күренде. Мәктәптә дә, дәрестән соң да гел бергә йөрүче бу ике малай бүген дә бер-берсенең аяк астына керердәй булып янәшә атлыйлар иде.

«Нинди бетмәгән сүзләре бар икән соң аларның?» — дип елмаеп куйды Гөлнара.— Бәхәсләшәләр бугай, әнә ничек бутыйлар кулларын».

Алар якындагы йортлар арасына кереп күмелүгә, авыр сумкасын күтәреп (ә анда ниләр барлыгын ул үзе дә белми), атлыйммы икән, юкмы икән дигән кыяфәттә Гөлнараның партадашы Салих күренде. Билгеле инде, малай бүген дә өй эшләрен эшләмәгән, шуңа күрә аның бер генә дә мәктәпкә барасы килми. Кичке караңгыга чаклы урамда шар сугып йөргәч соң! Өстәвенә әле кайткач, йоклап киткәнче, телевизор каршында утыргандыр. Телевизордан нәрсәләр караганын тәнәфестә сөйләргә ярата ул. Ә дәрес башланды исә — авызын тегеп куйганнармыни. Укытучы Нәфисә апалары сөйләргә бастыргач, урталай сынып төшә.

Гөлнара аны шефлыкка алган иде. Дәресләрен әзерләшергә булыша иде. Хәзер ялгызы гына утырадыр инде ул. Аңа булышырга атлыгып торучылар да бик юктыр.

Салихтан соң бүтән классташларын да күзе белән озатып калды кыз.

...Тиздән, менә барысын да дәрескә чакырып, кыңгырау шалтырар. Кулына класс журналын, дәфтәр-китапларын күтәреп Нәфисә апалары килеп керер. Ул күзе белән укучыларны барлап чыгар. Салих янәшәсендәге буш урынга карап алыр да Гөлнара фамилиясе турысына билге ясап куяр. Укытучы сөйли башларга теләп талпынып куяр да капыл гына тукталып калыр. Барысын да сискәндереп кинәт кенә ишек ачылып китәр. Аннан сулуы капкан, тирләп-пешкән Нәзир күренер...

Болары барысы да биш-алты минуттан соң булыр. Әлегә Нәзир өйләрендә киемнәрен эзләп бүлмәләр буйлап чабулыйдыр. Я бүреген, я ботинкасының бер сыңарын таба алмый изаланып беткәндер.

«Бүгеннән соң барысын да билгеле урынга куяр идем», дип үз-үзенә сүз дә биргәндер әле. Аны булдыра ул. Тик әлегә барысы да уенда гына кала килә.

Гөлнара бер сәгатькә, бер тәрәзәгә карап Нәзирнең күренүен көтте. «Дәрес башлана бит инде, их сине, Нәзир!» — дип үзалдына сөйләнеп тә куйды. Ниһаять, күренде малай. Бүреге баш очында гына эленеп тора. Менә төшеп кала, менә төшеп кала кебек күренә. Тунын төймәләргә дә вакыты калмаган.

Гөлнара классташларын күз карашы белән озатып бетергәч янә урынына ятты. Әмма күңеле класста иде. Әйтерсең лә ул иптәшләренә күренмичә генә дәрестә утыра. Дәрес... Нинди яңа темаларны өйрәнәләр икән, ә? Беләсе иде...

Бер-ике көн элек Сәлимәгә телефоннан шалтыратып бу хакта сораштырган иде. Тик классташы: «И-и, мәктәптәге хәлләрне телефоннан гына сөйләп бетерерлекме соң?! Вакыт табып яныңа кереп чыгармын, сөйләрмен әле»— дип чикләнде. Сәлимәне бик көткән иде югыйсә Гөлнара. Тик юкка. Вакыт таба алмыйдыр шул инде...

Гөлнара торып даруларын эчә дә янә уйга кала. Дәресләр тәмамланганчы шулай ята ул. Классташлары өйләренә таралышыр вакыт җиткәч кенә торып тагын тәрәзәгә каплана.

Бик канәгать елмаеп, тәрәзә яныннан эре генә узып китүче Сәлимәне каршы ала. Агылый белән Тагылый — Газим белән Вәзимнең — әле дә булса ни хакында бәхәсләшүләрен беләсе иде. Үзе дә шул бәхәскә кушылып китәр иде кыз. Ул да түгел, башы тагын да түбәнрәк иелгән Салихны күреп: «Син бер дә борчылма, «ике»ләләреңне төзәтергә үзем булышырмын, бергәләп әзерләрбез дәресне», дип юатасы килеп китә. Их, бүтән классташларын да күрсен иде дә, сезне бик сагындым, дип әйтсен иде ул...

Тик классташлары инәлеп-инәлеп әйтәсе килгән бу сүзләрне ишетү түгел, хәтта аның тәрәзәгә капланып моңаеп кына карап торганын да күрмиләр шул менә. Ул яши торган йортның стенасына орынып ук китсәләр дә Гөлнараны алар һич шәйләмиләр...

СЕРЛЕ АВАЗЛАР

Кичке эңгер-меңгер вакыт. Авыл башында, чирәмлектә, уйнап йөрүче малайлар тавышыннан тирә-юнь гөж килә.

— Мал-лай-ларр,— дип ыңгырашты шул чак арадан кемдер.

Барысы да, уеннарыннан тукталып, тавыш килгән якка карадылар. Бизгәк тоткан кебек калтыранучы малай Әүхәт иде. Мансур арада иң өлкәне. Ул Әүхәт янына йөгереп килде. Малайның йөзе агарып ук калган, тешләре тешкә бәрелүдән тирә-якка тагын да шомлылык өстәлә.

— Нәрсә булды сиңа, Әүхәт? Кем кыерсытты?! — диде ул һәм тирә-яктагыларга күз ташлады.

— Анда... иске тегермәндә... җенме, пәриме бар. Сызгырып, улап утыра,— диде Әүхәт өзек-өзек итеп.

Малайның бу сүзләрен ишеткәч, башка малайлар да өнсез калдылар. Ышанырга да, ышанмаска да белмәделәр.

— Юкны сөйләмәсәнә,— диде Мансур да исе китмәгән булып. Әмма ул гәүдәсе буйлап ниндидер салкын дулкын йөгергәнен тоеп алды.

Авылдан аз гына читтәрәк моңаеп утыручы иске тегермәнгә карап тын калдылар.

Тегермәннең эштән туктавына берничә ел инде. Онны хәзер күрше авылдагы яңа тегермәндә тарттыралар. Монысын сүтәргә әллә инде кызганалар, әллә куллары күтәрелми өлкәннәрнең.

Шул чак акрын гына җил исеп куйды. Һәм... һәм чыннан да тегермән ягыннан ниндидер аңлашылмаган авазлар чыгарып кемдер ыңгыраша, көлә, елый башлады... Мансур чүпрәк җилфердәгәндә генә була торган тавыш та ишеткәндәй булды. Малайлар ирексездән бер-берсенә сыена төштеләр. Әүхәт йөзендәге аклык, калтырану бүтәннәргә дә күчте.

Зиерәк тә арада өлкән санала иде.

— Курыкмагыз ла, бернинди җен, шайтан юк бу дөньяда,— диде ул. Тагын нидер әйтмәкче булып авызын ачкан иде дә өлгерми калды. Җил иске тегермән ягыннан да тагын зәһәррәк сызгырган, улауга, шыңшуга охшаган авазлар алып килде.

«Әллә малайларны авылга ияртеп йөгерергә инде?» — дип уйлады Мансур.— Юк, юк. Зиерәк дөрес әйтә: бернинди җен, шайтан юк. Бу турыда күпме китап укыганы бар ич инде. Ә алайса нинди серле тавыш соң бу?»



Ниһаять, телгә килде Мансур:

— Зиерәк дөрес әйтә. Җеннәр, шайтаннар юк нәрсә алар.

— Тегермәндә кем бар алайса? — диде шул тарафка күз атып Әнвәр, ә үзе малайлар тирәсенә елышарак төште.

— Әнә ич итәгеннән дә селки...— дип тагын да күңелгә шом салды Гафият.

— Әйдәгез, әтиләрне чакырабыз...— диде арада иң кечкенәсе Самат. Менә-менә авылга таба йөгерер кебек үзе.

— Ә нигә чакырырга, хәзер барам да үзем карыйм...— дип алга чыгып басты Зиерәк.

— Мин дә синең белән...— дип, Мансур да аның янына атлады. Зиерәкнең дустын кочаклап аласы, ягымлы сүзләр әйтәсе килде. Тик тыелып калды. Бары елмайды гына. «Дуслык шундый авыр минутларда санала ул»,— дип уйлады.

Малайлар тегермәнгә таба атладылар. Башкалар артта калды. Хәзер инде бары алга атларга. Туктарга һич ярамый. Мансур да, Зиерәк тә үз уйларына бирелгән. Ә каршыда серле булып иске тегермән күренә. Ул әкияттә сөйләнә торган сарайларны хәтерләтә. Тик бераз гына авыша төшкән...

— Фю-ю-ю... Ж-ж-ж-з-з...

Малайларның үзенә таба якынаюларын яратмагандай, тегермән ягыннан тагын да куркынычрак тавышлар ишетелде. Каядыр якында гына ябалак кычкырды. Ул да түгел тегермән түбәсеннән кычкырачырылдаша бер төркем кош күтәрелде...

Ниһаять, Мансур белән Зиерәк тегермән каршына килеп җиттеләр.

— Ишеге бикле,— диде Зиерәк ярым пышылдап.

— Тавыш теге яктан килә...

Алар акрын гына атлап тегермәннең икенче ягына

чыктылар. Йөзләренә көчле җил бәрелде. Бу юлы колак төбендә үк сызгыргандай иттеләр, шуннан икесе дә сискәнеп куйдылар.

Малайлар, соңгы кыюлыкларын җыеп, капчык белән капланган тәрәзә янына ук килделәр. Икесе бергә диярлек кулларын сузып тәрәзәдәге капчыкны тартып алдылар. Яңадан җил исеп куйды. Һәм Мансур белән Зиерәк серле тавышларның ватык тәрәзә пыялаларыннан чыгуын чамалап калдылар. Мансур таш алып тәрәзәнең исән пыяла кисәкләрен дә коеп төшерде.

— Җеннең итәге капчыктан тегелгән икән,— диде Зиерәк көлеп. Иске тегермән янына килеп җиткән бүтән малайлар да, аңа кушылып, дәррәү хихылдашып куйдылар.

КАЙНАР ДӘФТӘР

Әхтәм агайның йөзе тәмам җимерелгән, кара янган иде. Ул сикереп дигәндәй машинасына менде, кисәк кенә тартып ишекне япты. Шул шәпкә машинасын кабызмакчы иде, булмады. Авыр «КамАЗ»ы, йокысыннан уянырга теләмәгәндәй, ыңгырашып кына куйды. Болай да ачуы чыккан шофер теш арасыннан сүгенеп-сыкранып алды. Үзе берөзлексез педалгә басуын дәвам иттерде.

— Ачкычын борырга оныттыгыз бит,— диде Газим ишетелер-ишетелмәс,— ачкычын...

Әхтәм абыйсы утыргыч кырыена поскан малайга каш астыннан гына карап алды да ачкычка үрелде. Кулы тиюгә машина гүләп эшли дә башлады. Кисәк кузгалып киттеләр.

— Теләмәсәң җәяү кайтасың,— диде Әхтәм агай үз алдына сөйләнгәндәй.

Басу уртасында япа-ялгызы басып калган Рәхимҗанга атап әйтелгән сүзләр булса да, Газимга читен булып китте. Ул үзе дә сизмәстән ачык тәрәзәгә капланды, үрелә-үрелә артка карады. Рәхимҗанны күрмәкче иде. Тик никадәр генә каерылып карамасын, файдасы булмады. Машина ерагаерга өлгерде шул. Әнә басуны калдырып олы юлга да чыктылар.

Янә Әхтәм агайга күтәрелеп карады Газим. Тынычланып өлгергән бугай инде. Әнә гамьсез генә сызгырырга кереште. Аның янәшәсендә утыру малайның ачуын китерә башлады. Сөйләшсен иде ичмасам. Әллә бар аның өчен Газим, әллә юк. Ә үзе: «Вәгъдә...— дигән булды,— машина йөртергә өйрәтәм мин сине»,— диде. Моны исенә төшерәсе иде дә, Әхтәм агайның кызыл йөзенә, юан муенына карагач, тыелып калды. Җилдәй җитез йөгерүче машина кебек күңелендә мең төрле уй бөтерелергә кереште.

...Беркөнне мәктәптән кайтып килгәндә Газим белән Рәхимҗанны колхоз бригадиры Алмаз абыйлары туктатты.

— Ни хәлләр бар, егетләр?! — дип башлады ул сүзен.

Малайлар сизенеп алдылар: бригадир абыйлары ниндидер мөһим нәрсә турында сөйләшергә җыена иде ахрысы, әнә ич зурлап «егетләр» дип дәшә. Ялгышмаганнар икән.

— Сезнең ярдәм кирәк бит әле, егетләр,— диде Алмаз абыйлары.— Иртәгә колхозга машиналар киләчәк. Урман буендагы Олы басуга ашлама чыгара башлыйбыз. Кайсы шофер ничек эшләячәк — шуның исәбен алып барырга кирәк. Уйладым-уйладым да сезнең кулдан килә торган эш бит бу дигән фикергә килдем. Иртәгә ял көнегез. Я, ризамы?

— Риза, ник риза булмаска,— дип җавап кайтарды малайлар.

Алмаз абыйлары башка төрле җавапның булмасын алдан ук белгән, күрәсең — елмаеп куйды. Тик шундук җитдиләнде:

— Әмма гадел булырга кирәклеген онытмагыз. Берегезгә складлар янында торырга, икенчегезгә басуга барырга туры килер. Ашлама тәртип белән сибелсен...

Газим белән Рәхимҗан иртәгесен таңнан ук торып ашламалар складына киттеләр. Алмаз абыйлары күптән шунда икән инде. Озакламый бер-бер артлы тезелешеп машиналар да килеп җитте. Бригадир күрсәтмәләр бирүгә эшкә дә керештеләр.

Ашлама төягән машиналарның берсенә утырып Рәхимҗан Олы басуга китеп барды. Ул кемнең күпме ташуын шунда санап торачак, кайда аударырга кирәклеген күрсәтеп торачак. Газимнең бурычы — моннан кузгалып китүчеләрне исәпкә алу иде. Әллә ни авырлыгы, катлаулыгы булмаса да җитди эш иде бу. Төяп торучы трактор үзенең зур чүмече «әх» дигәнче әрҗәне тутырып та өлгерә. Машиналарның берсе кузгалып китүгә, икенчесе килеп баса. Бутамаска, йөк төяп кузгалган һәр машинаның номерын дөрес итеп язып барырга кирәк.

— Соңыннан шуның буенча шоферларга хезмәт хакы түлибез,— дигән иде Алмаз абыйлары. Тырышты Газим. Шофер абыйлары да сизеп өлгерде бугай моны. Малайга гел елмаеп карыйлар, яныннан кычкыртып узалар да басу ягына элдертәләр. Машиналар өзлексез килә-китә торгач, өем-өем булып яткан ашлама күзгә күренеп кимеде. Һәм... һәм шунда бер нәрсәгә игътибар итте Газим. Шофер абыйларның берсе ашыкмый-кабаланмый гына йөри. Пошмас инде менә. Ашламаны да күп төятми. Әрҗәгә бер-ике чүмеч салуга кузгалып китү ягын чамалый. Бер әй-

ләнеп килде әлеге машина шулай, икенче тапкыр урап кайтты.

Газимнең үзенә өнәми каравын теге агай да сизде, күрәсең. Бармагы белән ишарәләп, Газимне үз янына чакырды.

— Нәрсә кәефең китте? — диде гөрелдәп.— Күңелсездер санап торуы, ә?!

Газимнең аңа барысын да әйтеп бирәсе, башкаларга салынып кына йөрисең, диясе килде. Авызын да ачкан иде инде. ,Өлгерми генә калды. Шофер агай әйтерсең күңелендәген укып бирде.

— Борчылма, тиздән эш бетәчәк. Үзеңне машина йөртергә өйрәтермен.

Монысын ук көтмәгән малай тәмам аптырашта калды. Күңелендәге төртмәле сүзләрне җил очыртып алып китте диярсең. Берсе дә калмады. Киресенчә: «Яхшы абый икән ич бу. Ә мин тагы...» — дигән уй балкып узды.

Чират көтеп торучы машиналарның сабырсызланып кычкырта башлауларын ишеткәч, Әхтәм агайга (шоферның исеме шулай иде) кузгалып китүдән башка чара калмады.

Газим исә, машина йөртү турында татлы уйларга чумып, аның кайтуын көтә башлады. Тик Әхтәм агайны шактый көтеп алырга туры килде аңа. «Нигә шулай акрын йөри икән ул? Машинасы да төзек, башкаларныкыннан яңарак та күренә югыйсә...» Газим тизрәк Әхтәм агай машинасына менеп утырырга хыяллана иде. Ниһаять, ул бәхетле минутлар килеп җитте.

Шофер абыйның ым кагуы булды, түземсезлеге югала башлаган малай җәһәт кенә кабинага менеп тә утырды. Иркен иде кабина эчендә, рәхәт иде.

Газимнең тизрәк рульне үзенә аласы килде. Әмма Әхтәм агай гына ашыкмады. Гүя ул юлдашының ме-

нә үреләм, менә сузылам дип торган кулларын күрмәмешкә салыша иде. Ике арадагы — утыргычта яткан дәфтәргә ымлады Әхтәм агай.

— Күпме юл ясаганмын? Кара әле, энекәш?! — диде.

Әлеге сүзләрне ишеткәч айнып киткәндәй булды малай. Дәфтәрне кулына алды. «Нигә кыланып сорап торган була. Болай да билгеле ич...» дигән уй йөгереп узды башыннан. Дәфтәрне кысыбрак тотты. Әйтерсең лә аны Әхтәм агай тартып алыр кебек иде. Газим читкәрәк елышуын үзе дә сизми калды. Ә менә Әхтәм агай аның эчке халәтен шундук абайлап алды.

— Машина шәп минем, ә? — диде ул. Ике кулы белән рульгә сугып куйды.— Менә йөртеп карагач, үзең дә күрерсең әле...

Һәм ул бер дә урынсызга кычкырып көлеп җибәрде. Кисәк кенә туктады да:

— Тик аңынчы минем исемгә өч-дүрт рейс өстәп куярсың, яме? — диде.

Газим дәшмәде. «Әллә соң?» — диде эченнән, күңеле кузгалып. Машина йөртергә бик өйрәнәсе килә иде шул.

— Чыннан да өйрәтәсезме? — диде ул ышанмагандай.

— Әйткән сүз — аткан ук,— диде Әхтәм агай, юлдашына серле елмаеп карады.

«Нигә шулай куркам әле? Беркем дә сизми бит», дигән уйдан тынычланып калды малай һәм, дәфтәрен ачып, шофер агайга берничә йөкне өстәп куйды. Ул арада машина Олы басуга килеп җиткән иде инде.

Басу өстендә өем-өем ашлама сибелгән. Рәхимҗанның тырышлыгы да бардыр монда. Бу кадәр тигез таратылмас иде. Эрегәч, бер генә карыш җир дә уңдырышсыз калмас болай булгач.

— Соңгысын алып килдек,— дип кычкырды Газим, тәрәзәдән дустына кул болгады.

Рәхимҗан күрсәткән урынга килеп туктадылар. Әхтәм агай кнопкаларның берсенә басуга әрҗә күтәрелде. Ашлама җиргә сибелде.

Хәзер инде кайтыр юлга гына борыласы калган иде. Ул чакта рульгә Газим утырган булыр. Тик нигәдер кайтырга ашыкмый иде шофер агай. Ул бер Газимгә, бер Рәхимҗанга карап тора әнә. Аннары:

— Дустыңның да машина йөртергә өйрәнергә исәбе юкмы? — диде.

Кайсы малай теләмәс машина йөртергә?! Рәхимҗанның да теләге бик зур.

— Без Газим белән килештек инде,— диде Әхтәм агай машина тирәсендә кайнашкан Рәхимҗанга.

Малай бернәрсә аңлашмыйча әле Газимгә, әле юантык гәүдәле Әхтәм агайга карап алды.

— Теге, ни...— дип, сүзне нәрсәдән башларга белми, тотлыгып торды Газим. Аннары Әхтәм агай куйган таләпне әйтеп салды.— Өч-дүрт рейс өстәп языйк әйдә. Мин инде...

Газим дәфтәргә күрсәтте.

Рәхимҗанның гаҗәпсенгән күзләрендә кинәт нәфрәт чаткылары җемелдәп китте.

— Син... Ничек инде эшләнмәгәнне эшләде дип язарга? Оныттыңмыни Алмаз абый нәрсә диде? Ул әйтмәсә дә...

Моңа кадәр астан гына карап торган Әхтәм агай да телгә килде:

— Курыкмасана шулай. Басуга чыгып сезнең өемнәрне санап йөрерләр дисеңме әллә? Җир күпне сеңдерә ул. Ничаклы өстәп язсаң да күтәрә...

— Юк, күтәрми. Күтәрергә тиеш түгел...— диде Рәхимҗан.

Болай эшләүнең намуссызлык икәнен әйтәсе, дус-

тым дип йөргән Газимне битәрләп авыр сүзләр кычкырасы, Әхтәм агайны эттән алып эткә саласы килде аның. Тик менә телсез калган иде шул. Бары:

— Их, сез!..— дип кенә куйды.

— Киттек әйдә, Газим,— диде Әхтәм агай.— Бик ялынып торабыз сиңа...

Олы басудан ераклашкан саен тынычсызлана бара Газим, сулыш алуы кыен аңа. Югыйсә ишек тәрәзәсен дә ачып куйды бит инде. «Нигә утырып киттем, нигә Рәхимҗан белән калмадым?» — дигән уй башын авырттыра иде. Ул арада Алмаз абыйсы күз алдына килде. Аның: «Гадел, намуслы булырга кирәклеген онытмагыз, егетләр», дигән сүзләрен кабат ишеткәндәй булды, һәм кулына тоткан дәфтәре кинәт утлы күмер шикелле пешереп алгандай итте.

— Туктатыгыз машинаны! — диде ул гамьсез генә сызгырып барган шоферга.

Әхтәм агай гаҗәпсенеп Газимгә карап алды. Малайның очып кунарга әзер торуын күреп тормозга басты.

— Әллә өйрәнми калырмын дисеңме?! «КамАЗ»ын да, бүтәнен дә йөртермен әле мин!..— диде Газим калтыраулы тавышы белән, кабинадан сикереп төште дә, кулы белән җилдән ышыклана-ышыклана, Олы басу ягына китеп барды. Тизрәк-тизрәк Рәхимҗан белән очрашасы килә иде аның.

ЙОЛДЫЗЛЫ КӘШӘКӘЛӘР

Ул чакта Ринат дүртенче класста гына укый иде әле. Кышкы каникул көннәре иде. Малайлар иртәдән кичке караңгыга кадәр шугалакта алка куа. Алар уйнаган боз өсте ялтырап тора, нәкъ көзге төсле

Кичен өйләргә таралырга җыенганда гына яннарына бер егет килеп туктады. Кулында кәшәкәсе дә бар. Яңа түгел-түгелен, шактый кыршылган. Сабына йолдыз сурәте төшерелгән. Хәтта бишәү! Ринат шуларга карап уйлап куйды: «Нәрсә аңлата икән алар?» Гади кәшәкә генә түгел инде болай булгач. Ниндидер сере бар...»

Ринатларның пионер отрядында да шундый матур гадәт яши. Кайсы звено атна буе «өчле»сез укый, шул звеноны мактап, өлгереш экранында кызыл йолдыз кабына...

Таныш булмаган абый малайларга күз ташлап чыкты да карашын Ринатка текәп тукталып калды.

— Яхшы уйныйсыз, егетләр,— диде ул, ниһаять, телгә килеп.— Эш чыга сездән. Тик менә «Алтын алка» уйнауның тәмен белеп бетермисез икән. Хәер, моңа ирешү авыр түгел. Бозга аяк баскач, анысын гына җиңә аласыз инде. Спорт клубына язылырга кирәк сезгә...

Егет Ринатка бер-ике адым ясады. Кулын малайның җилкәсенә салды.

— Исемең ничек әле синең?

— Ринат ул...— дип шаулашып аның өчен дуслары җавап бирде.

— Менә нәрсә, Ринат,— дип сүзендә дәвам итте абый.— Синең уйнавыңны берничә көн күзәтәм инде мин. Син «Акчарлак» командасына бар. Мин элек үзем шунда уйнаган идем...

Малайның талчыккан йөзе яктыра төште. Шулай булмыйча, «Акчарлак» командасы турында белмәгән, ишетмәгән кеше юктыр ул шәһәрдә. Күпме ярышларда катнашып, җиңеп чыктылар акчарлаклылар. Кәшәкәдәге кызыл йолдызлар «Акчарлак»ның зур ярышларда җиңүен аңлата инде алайса...

Ринат янә каршында басып торучы абыйга күтә-

релеп карады. Егет малайның кәшәкәдән күзен алмавын искәртеп өлгергән иде бугай. Ул Ринатка кулындагы кәшәкәсен сузды:

— Мә, энем, ал син аны. Уңышлар китерсен ул сиңа...

Малай тылсымлы кәшәкәгә ике куллап үрелде. Аны алгач, үзен үсеп, зураеп киткәндәй тойды. Янәшәдәге малайлар да җанлана төштеләр. Һәркемнең бүләкне якыннанрак күрәсе, тотып карыйсы килә иде. Шау-шу тынгач, Ринат тирә-ягына карады. Әле яңа гына елмаеп басып торган абый әкияттәге кебек юкка чыккан иде. Ринат үкенеп куйды. Исемен сорарга да башына килмәде, рәхмәт әйтергә дә онытты. Малай, караңгылыкны сискәндереп:

— Сынатмаска сүз бирәм! — дип кычкырып җибәрде.

Тавышы кайтаваз булып якындагы биек өйләрнең тәрәзәләренә кагылып үтте дә шугалакның көмеш бозында оеп, тынып калды.

* * *

Каршысына кечкенәрәк буйлы, янып торган йөзле малай килеп баскач, Әнәс Наилович Ногманов җитдиләнә төште.

— Мин Ринат Закиров булам. Алтынчы мәктәптән, дүртенче класста укыйм. Сезнең клубка йөрергә телим..

Малай өзек-өзек сөйләргә кереште. Ә үзе кулындагы бүләк кәшәкәне кысып тоткан. Әйтерсең тренер аны кире борыр да, ул кулындагы кәшәкәсен төшереп җибәрер төсле

— Таныш та кебек ..— диде Әнәс Наилович кәшәкәгә ишарәләп

Ринат кичә булган хәлне төкми-чәчми сөйләп бирде.

— Алайса сине «Акчарлак»ка алмый ярамас,— диде тренер, малайны тыңлагач, һәм өстәп куйды: — Үзеңнең йолдызларыңны булдырыр өчен сиңа бик нык тырышырга туры киләчәк. «Акчарлак» шәһәребез данын гына түгел, республикабыз данын да яклап көрәшүче команда ул...

Тренер җиңүдә яулап алынган күп санлы кубоклар белән таныштырды.

— Аларның санын ишәйтү, команда данын саклау хәзер сиңа да бәйле булачак,— диде тренер сүзен тәмамлап.

Ринат кулындагы кәшәкәсенә карады. Монда килгәч өр-яңаны бирделәр аңа. Йолдызлар төшерелмәгәнне...

Тренировкадан очынып, канатланып кайтты малай. Хоккей уйнауның бик күп серләре бар икән. Элек алканы һәркем үзенчә куа иде. Ә хәзер мәйданчыкта һәр уенчының үз урыны бар. Тренер Ринатны һөҗүмче итеп билгеләде. Кышкы көннәр малай өчен бик эссе булды. «Акчарлак» байтак ярышларда катнашты, җиңелү ачысын да татыды. Җиңү бәхетен дә кичерделәр. Ә һәр җиңү Ринатның кәшәкәсенә кызыл йолдыз булып уелып калды.

Ринат белә хәзер: җиңүләрнең сере — малайларның бер йодрык булып берләшүләрендә, дус яшәүләрендә.

...Беркөнне Ринат тренировкадан кайтып килә иде. Каршы ишегалдындагы шугалакта кәшәкә куып йөргән берничә бәләкәй малайны күреп, туктап калды. Әнә берсе, башына зәңгәр башлык кигәне, яшен ташы кебек, боз өстендә оча. Алка да гел аның кулында. «Акчарлак»ка чакырырга кирәк үзен»,— дип уйлады Ринат шунда. Малайлар да, моны сизенгәндәй, уйнаудан туктадылар. Кәшәкә тоткан абый янына җыел-

дылар. Зәңгәр башлык Ринат кулындагы кәшәкәгә карады. Аның сабындагы йолдызларны саный иде бугай ул.

— Яхшы уйныйсыз, малайлар,— дип башлады Ринат, кайчандыр үзләре белән булган хәлне искә төшереп. Аннан соң зәңгәр башлыкка борылды.— Безнең «Акчарлак»ка кил син.

Малай ышаныргамы-юкмы дигәндәй, Ринат абыйсына карады. Ринатның җитди карашын күргәч, бербер артлы сораулар яудырырга кереште. Җавапсыз калдырмады егет яңа танышының сүзләрен. Бәйнәбәйнә үзләренең командалары турында сөйләде.

— Мә, истәлегем булсын, сине җиңүләргә рухландырсын,— диде аннары Ринат һәм йолдызлар уелган кәшәкәсен малайга сузды...

ЛЕНИН ТАВЫ

Җил капканың шыгырдап ачылуыннан Сәгыйдулла карт башын күтәрде. Оныгы Фәрит икән. Уйнак җил малайның чәчен тузгыткан. Чалбар балакларын тезенә кадәр сызганып куйган ул. Кулында — көрәк.

— Бу кем, минәйтәм, танымый да торам үзеңне,— дип каршы алды аны бабасы. Шаяртып тагын нидер әйтмәкче иде дә, Фәритнең җитди йөзен күргәч, туктады. Алъяпкычын төзәтә-төзәтә оныгы каршына атлады.

— Бабай, без Олы тауның исемен үзгәрттек. Ул бүгеннән — Ленин тавы...

— Кемнәр инде ул «без» дигәнең?

— Җиденче «А»лар,—диде малай һәм койма буендагы бүрәнә өстенә килеп утырды.

— Бүген классыбыз белән Олы тауга мендек,— дип сөйләргә кереште Фәрит,— барыбыз бергә мен-

гәнебез юк иде әле. Олы таудан авылыбызны күзәттек. Як-ягына агачлар тезелгән урамнар, авыл куенына сыенып агучы елга... Гел рәсемдәге кебек...

Сәгыйдулла карт та оныгы янәшәсенә чүгәләде.

— Укытучы Рәйсә апа авылыбызның тарихы белән таныштырды. Революциягә кадәр бигрәк фәкыйрь яшәгән икән безнең авыл. Хәзергедәй төзек йортлар Борһан байда гына булган. Элек тирә-яктагы бөтен байлык — урманнар, болыннар, хәтта Олы тау да Борһан байныкы иде, дип үзеңнең дә әйткәнең бар иде бит, бабай...

— Аларның барысын да Ленин бабай алып бирде безгә,— диде Сәгыйдулла карт. Үзе, нәрсәнедер исенә төшерергә теләгәндәй, күзен бер ноктага төбәде.

Фәрит урыныннан торды.

— Бабай, әйдә «Ленин тавы»н карыйк әле. Ул хәзер тагын да биегәйгән кебек...

Алар урамга чыктылар.

Сәгыйдулла карт, кулын каш өстенә куеп, тау ягына карады. Анда, яшел чирәм белән капланган тау өстендә, зур хәрефләр белән язылган «Ленин» дигән сүзне укыды.

«Фәритләр эше», дип уйлады карт.

— Һәр язны Ленин тавына агачлар утыртырбыз, анда бакча ясарбыз,— диде Фәрит, бабасының уйларын сизенгәндәй.

— Олы тау — Ленин тавы,— дип куйды Сәгыйдулла карт үзалдына.

...Олы тау! Авыл каршындагы әлеге бердәнбер тауны Сәгыйдулла картның малай чагыннан бирле шулай атыйлар. Авыл тарихы белән бәйле бөтен вакыйгаларга шаһит ул. «Патша төшерелгән!» — дигән хәбәр килгәч үк, кемдер Олы тауга кызыл байрак менгереп кадады. Сәгыйдулла ялан аяклы малай гына

иде әле ул чакта.,Өлкәннәргә ияреп ул да Олы тауга — кызыл байрак янына йөгерде. Таныш булмаган бер кеше җыелган халыкка кызып-кызып нидер сөйли иде. «Җир! Тынычлык! Ленин!» — дигән сүзләрне кечкенә Сәгыйдулла беренче мәртәбә шунда ишетте, ләкин аларның мәгънәсен генә аңлап бетермәде. Шулай да хәзер инде авылдагы барлык нәрсәләргә Борһан бай хуҗа булмавын, аларның авыл кешеләре кулына күчүен төшенде ул.

Олы тауда булган җыеннан соң берничә ел үткән иде. Чатлама суык кышның аяз бер көне. Бөтен бала-чага Олы тауда чана шуа. Араларында Сәгыйдулла да бар.

— Чапкын килә, чапкын! — дип кычкырды шул чак кемдер. Барысы да тавыш килгән якка борылдылар.

Чыннан да, олы юлдан берәү җан-фәрманга атын куа иде.

— Ленин вафат булган...

Җайдак үз артыннан кеше ышанмаслык хәбәр калдырып узды.

Бу сүзләрдән таудагы балалар өнсез калдылар. Сәгыйдулланың күз аллары караңгыланды. Кулыннан чана бавы ычкынды. Чанасы түбәнгә очты...

Кызыл байрак тирәсенә тагын халык җыелды.

— Ленин бабай исән! Олы тау — безнеке! — дип кычкырып җибәрде нәни Сәгыйдулла.

«Ленин исән...»

Сәгыйдулла карт уйларын ишетерлек итеп әйткән икән.

Менә хәзер оныгы Фәрит тә:

— Әйе, Ленин бабай исән! — дип аны җөпләп куйды

Алар бераз сүзсез тордылар да икәүләшеп Ленин тавына таба атлап киттеләр

УТКӘННӘРНЕҢ МОҢЛЫ ХАТИРӘСЕ

...Утыз беренче елның салкын, яңгырлы көзе. Урам уртасыннан пычрак ерып бер кыз килә. Өстенә кигән бушлатының изүләре ачылып китүенә дә, кызыл яулыгының башыннан шуып артка төшүенә дә игътибар итмичә, кызу-кызу атлый ул. Ерак җирдән кайтып килеше, күрәсең. Кара чәченнән пар бөркелә. Урамда очраган кешеләр аның үзенә дә, кулына кысып тоткан төенчегенә дә гаҗәпләнеп карап калалар. Ул һаман ашыга. Тизрәк авыл башындагы мәктәпкә, укучылары янына кайтып җитәсе килә.

Әлбәттә, күңеле белән ул әллә кайчан кечкенә дуслары янында. Аларга сөйләячәк сүзләре дә әзер инде.

— Балалар, мин волостька бардым,— дип башлаячак ул сүзен.— Анда яңа тормыш төзү турында сөйләштек. Әлбәттә, бу эшнең башында пионерлар да торырга тиеш, чөнки алар киләчәкнең хуҗалары бит...

Шуннан соң укытучы үзе белән алып кайткан әлеге серле төенчекне чишеп җибәрәчәк.

— Истәлек өчен безгә менә шушы барабанны бүләк иттеләр,— диячәк...

— Итәгеңә ул каптымы әллә? Нигә шулай чабасың?!

Укытучы, кисәк кенә әйтелгән сүзләрдән сискәнеп, тукталып калды. Күтәрелеп караса, каршында инде берничә ел элек авылдан сөрелгән Сәйфи бай басып тора. Укытучы кыз аны чак-чак кына таный алды. Сәйфинең йөзен сары сакал-мыек баскан. Кечкенә яшькелт күзләре тоныкланып калган. Ул кулындагы тәмәкесен кысылган иреннәренә китереп озак кына суырды да төтенен кызның йөзенә өрде.

— Минем өйгә тәмам хуҗа булып алгансың бит,

әй. Авыл аңгыраларын аң-белемле итмәкче буласың инде, ә? — диде ул укытучы кулындагы төенчеккә карап һәм үз алдына мыгырданып куйды.— Тагын нәрсә күтәргән инде бу?

Кыз, тәмәке исенә сулышы буылып:

— Ялгышасыз, абзый, ул сезнең өегез түгел. Халыкныкы,— диде.— Хәзер анда мәктәп, тик яңасын салганчы гына...

— Алай күп сөйләнмә, кызый. Юньле чакта минем өйне ташла да авылдан бөтенләй чыгып кит...

Кинәт аның кысык күзләре ачылып китте. Алардан үч, янау очкыны сибелде.

— Мин китәр өчен килмәдем,— диде кыз тыныч кына.— Сезне дә кайтырга җибәрмәгәннәр иде бит. Ничек кайттыгыз әле?!

Сәйфигә бу ошамады, күрәсең. Ул тирә-ягына каранып алды да, кабаланып, тыкрыкка кереп китте. Күз ачып йомганчы юк та булды. Волостьтан килгән милиционерлар аны эзләп тә карадылар. Тик Сәйфи табылмады...

* * *

Стенага эленгән барабанның кысаларында нурлар уйный. Кечкенә генә бүлмәне күзәтә ул шулай.

Әнә өстәл янында укытучы кыз Нәҗия укучыларның дәфтәрләрен тикшерә. Инде кайчаннан бирле утыра, ник бер күтәрелеп карасын. Хәтта яңгыр тамчыларының тәрәзәгә чиертүен дә ишетми.

Ниһаять, лампа маеның бетә баруын сизгәч, кыз башын күтәрде. Акрын гына кулларын хәрәкәтләндерде. Стенадагы барабанны кулына алып, кыска гына бер көйгә суккалап торды. Аның күз алдында әле берничә көн элек кенә авылда Совет властеның ундүрт еллыгын билгеләп үтүләре җанланды.

...Авыл кызыл әләмнәргә күмелгән. Урамда балаларның җырлаганы ишетелә. Җырга дәртле барабан тавышы да кушыла...

Нажия яңадан урынына килеп утырды. Барабанны өстәлгә куеп, тынып калды.

Барабан телсез шул. Әгәр аның теле булса хәзер ул бар көченә:

— Укытучым, саклан, сак-л-а-а-н-н! Ә сез, авылдашлар, уяныгыз!!! — дип кычкырыр иде.

Тышта нәрсәдер шалтырап куйды. Ул да түгел ишектән Сәйфи атылып керде дә мәче тизлеге белән укытучы кызның авызына тәмәке исе сеңгән кулын каплады. Тонык ут яктысында хәнҗәр ялтырап алды. Барабан өстәл өстеннән дыңгырдап төште дә, идән буйлап тәгәрәп китте. Сәйфи аягы астында калып ыңгырашкач, тынып калды...

Кешеләр килгәндә авыл башындагы ялгыз йортны ут чолгап алган иде инде...

Әнә шул йортның нигезе урынында, ташлар, күмерләр арасында авылның беренче пионерларына бүләк ителгән революцион барабанның кыршаулары, яшь-яшь укытучы кыз турында хәтер ята...

МИНЕМ ӘБИЕМ

Җәмит шатланып, канатланып кайтып керде. Күренеп тора: куанычы эченә сыймый.

— Әби, «бишле» алдым, сочинениедән,— дип тезеп китте ишектән керә-керешкә.

Оныгының көн саен диярлек «дүртле», «бишле» алып кайтуыны гадәтләнгән иде инде Кәүсәрия әби. Әмма Җәмит башка көннәрне үзенең билгеләре белән мактанып тормый иде. Ә бүген...

Әбисе, эшеннән аерылып, урыныннан кузгалды. Малай янына килеп йомшак кына аркасыннан кагып алды.

— Уңган шул, булган шул минем улым,— дип аның шатлыгын уртаклашырга ашыкты.

Оныгы, чишенеп киемнәрен пөхтәләп урнаштыргач, сумкасын ачып дәфтәрләр тартып чыгарды.

— Мә, укып кара әле, мин анда синең хакта яздым,— дип берсен әбисенә сузды.

Кәүсәрия әби ул кадәресен үк көтмәгән иде. Ул әле дә булса бәхет кошы тоткандай басып торган Җәмиткә, шаярмачы, дигән сыман карап алды да, өстәл янына узып, күзлеген киде һәм кулындагы дәфтәрне карарга кереште.

Язма эшләр дәфтәре икән. Әле диктант, әле изложение язганнар. Соңгысы менә сочинение, ирекле темага, диелгән.

Кәүсәрия әби тигез итеп, бер якка авыштырыбрак язылган сүзләрне укырга керешге. «Минем әбием» дип исемләнгән иде язма. Оныгы күңелендә йөрткән уй-хисләрен түкми-чәчми ак биткә тезгән.

«Минем Кәүсәрия әбием турында белмисез әле сез. Шуңа күрә дә бүген сезне аның белән таныштырырга булдым,— дип башлаган Җәмит үзенең сочинениесен.— Уртача буйлы, ачык йөзле, чәчләренә чал кунган кеше ул. Аның эшсез утырганын һич күрмәссең. Әле җылы оекбашлар бәйли, әтиәниемә дә булышырга вакыт таба. Үзенең акыллы киңәшләрен дә бирә ул. Барысына да ничек өлгерә диген! Юкса фабрикага барып эшләп тә кайта бит әле.

Кайчак әтием аңа: «Әни, азрак ял итеп алыр идең»,— ди. Аның тыңларга исәбендә дә юк. «Ничек кул кушырып утырмак кирәк»,— дип кенә җавап кайтара.

Минем әбием бик күп авырлыкларны җиңгән. Сугышны да үз күзе белән күргән. Аңа ул чакта бары ундүрт кенә яшь булган...

Бу юлларны укыганда Кәүсәрия әбинең күңеле нечкәреп китте.

«Күрче ничек килештергән,— дип уйлады ул.— Әйтәм җирле соңгы көннәрдә баш та күтәрми утырды. Сугыш елы истәлекләремне дә кат-кат сораштырды».

Әйе шул, сугыш башланганда ул Җәмиттән аз гына өлкәнрәк иде. Ул чакта алар Одесса шәһәрендә яшиләр иде. Фашистлар шәһәрне басып ала башлагач, ул да әнисе белән бик күп хатын-кызларга, карт-корыга ияреп, Одессаны ташлап китәргә мәҗбүр булды. Әмма ерак китәргә өлгермәделәр. Юлда аларны гитлерчылар уратып алды. Этә-төртә бөркәүле машиналарга төяделәр дә каядыр алып киттеләр. Соңыннан ачыкланды, ерак та түгел тимер юл депосы хәрабә хәленә килгән, фашистлар шуны сафка бастырмакчылар икән.

Килеп туктагач, ямьсез итеп кычкырган фашистлар аларны машиналардан куып төшерделәр дә һау-һау өргән этләр сагы астында кирпеч төяргә куштылар. Бер-берсенә охшаган шыксыз, күңелсез көннәр башланды. Аркага асылган агач тартмага биш-алты кирпечне куясың да йөгерәсең. Иртә таңнан кичке караңгыга кадәр шулай дәвам итә.

Беркөнне шулай әнисе ябыгып, йончып калган кызына ярдәм итмәкче булды. Сакта торучы озын буйлы, карчыга борынлы немец солдаты Кәүсәриянең әнисен чәченнән урап тотты да читкә алып китте. Авызыннан төкерекләрен чәчә-чәчә сүгенергә, типкәләргә кереште. Ярый әле, ярдәмгә хатын-кызлар килеп өлгерде. Канга баткан әнисен көч хәл белән фашисттан аралап алдылар.

Берничә көннән кыз янына таныш булмаган бер абый килде.

— Әниең исән, син бик үк борчылма, яме! Ул ышанычлы кулларда...— диде.

Моңа кадәр үз-үзенә урын таба алмаган кыз өчен моннан да җылы хәбәр булуы мөмкин түгел иде. Ул, күз яшьләренә төелеп, аның киң күкрәгенә капланды.

— Кәүсәрия,— дип дәвам итте таныш булмаган абый,— безгә синең ярдәм кирәк. Менә бу хатны урманга — безнең егетләргә илтеп тапшыр әле...

Кәүсәриянең беренче сугышчан бурыч үтәве әнә шул хатны илтеп тапшырудан башланган иде. Күп ташылды аннан соң да хатлар. Станция аркылы ничә поезд үтүен, аларның нинди йөк ташуларын партизаннар вакытында белеп тора башладылар. Фашистларның йөк төягән поездлары еш кына күккә оча башлады...

Кәүсәрия әби хәтер йомгагын сүтә бирде. Мең тугыз йөз кырык өченче елның 23 феврале әле дә күз алдында аның. Бу көнне истәлекле итеп билгеләп үтәргә булган иделәр.

...Кәүсәрия сәләмә киемнәргә төренде дә гитлерчылар яши торган йорт янына китте. Ашарга соранган булып сакта торучы немец солдаты каршысына барып басты. Тегене сөйләндереп, игътибарын читкә тартырга кирәк иде. Шулай булды да. Ул арада ике иптәше йорт урнашкан мәйданга уздылар, әрҗәләр өеме артына яшеренделәр. Төнгә кадәр качып ятарга, караңгылангач, йорт түбәсенә менеп, Кызыл байрак кадарга тиеш иде алар. Иртәгесен ал комачны күреп, кешеләр бер-берсенә карап елмаештылар. Фашистлар исә болгатылган кырмыска оясыдай арлы-бирле чаптылар. Байракны алырга җөрьәт итүче табылмады. Чөнки биек түбәгә алып менүче бердәнбер бас-

кычка: «Сак булыгыз, мина!» дигән язу бөркетелгән иде. Бу фашистларны куркыту өчен генә, юкса анда бернинди дә мина куелмаган иде.

Еллар үтсә дә Кәүсәрия әби сугыш елларында күргән мәхшәрләрне онытмый. Әйтерсең лә утлы хәтер булып җанда көйри алар.

Кәүсәрия әби, уйларыннан арынып, оныгы язган сочинениегә иелде.

«...Әбием тынычлыкны белергә, аны сакларга әзер булып үсәргә куша. Мин тынычлыкның нигә кирәклеген аңладым инде».

Бу минутларда Кәүсәрия әбинең йөзендә елмаю балкый иде.

ҖӨТЕЛМӘГӘН СОРАУ

Рәсим күтәрелеп караган иде, алгы партада утырган Илһамның ручкасына күзе төште. Гади генә дә түгел, бизәкләп, сырлап ясалган иде ул. Тәрәзәдән сузылган кояш нурларында алтындай елык-елык килә. Уйнаклаган нурлар Рәсимне: «Синең андый ручкаң юк»,— дип үчекләүләр сыман иде.

Тора-бара әлеге ручка малайның тәмам тынычлыгын алды. Аңа карап утыра торгач, кыңгырау шалтыраганын да ишетмәде. Малайлар ишектән йөгереп чыга башлагач кына кайда утыруын абайлап алды.

Әнә Илһам да ручкасын кесәсенә салып ишеккә юнәлде. Рәсим аның артыннан көнләшеп карап калды. Шул минутта күңелендә бер уй кузгалды. Әлеге ручканы үзенеке итү теләге иде ул.

Тәнәфес вакытында да, кыңгырау шалтырап икенче дәрескә кереп утыргач та малай гел шул хакта баш ватты. Дәрес буена күзе алдагы партада — ни-

дер сизенгәндәй Илһам кулына сыенган ручкада булды. Аңа караган саен теге кара теләк арта гына барды.

Дәресләр тәмамлануын белдереп янә кыңгырау тавышы бирелүгә, Рәсим ашыкмый-кабаланмый урыныннан торды. Сумкаларына дәфтәр, китапларын тутыру белән мәшгуль булган Илһам ручкасының юкка чыкканын сизми дә калды. Рәт арасыннан узганда Рәсим үзенең тынычлыгын алган ручканы эләктергән иде инде. Ничек шулай оста, тиз эләктергәндер, соңыннан үзе дә гаҗәпләнде ул моңа. Аны-моны уйламаган Илһам сумкасын күтәреп класстан чыгып китте.

Рәсимнән дә бәхетле малай юк иде бу минутларда. Бизәкле ручка аның кесәсенә кереп кунаклаган иде.

Өйләренә дә алтын кош тоткандай очынып кайтып керде. Кесәсеннән ручканы алып әйләндереп-тулгандырып карарга кереште. Бигрәкләр дә матур, язарга да иплe. Шушы ручканы үзенеке итүенә гел сөенеп, шатланып йөрер кебек иде малай. Тик куанычы озакка бармады.

Барысына да сеңлесе Илгизә сәбәпче булды. Абыйсы кулындагы ручканы кай арада күреп алган диген. Янәшәсенә килеп тә басты, шәрран ярып сорап та куйды:

— Ай нинди матур ручка. Кайдан алдың аны, абый?

Бу көтелмәгән сорауга ни-нәрсә дип тә җавап бирә алмады Рәсим. Алгы бүлмәдән әнисе килеп чыкты. Ул да улы кулындагы ручканы күреп шул ук сорауны кабатлады. Рәсим тәмам коелып төште. Әле бая гына ручканы үзенеке итүенә сөенеп туя алмаган иде. Хәзер менә җавап бирә алмый, башын аска иеп тик басып тора. Йөзе комач кебек кызыл.

— И-и-и, улым, күреп торам, кеше әйберенә ти-

гәнсең. Кара аны, иясенә илтеп бир,— диде әнисе һәм кисәк кенә борылып бүлмәдән чыгып та китте.

Рәсим янә учына күз салды. Ручка элеккечә балкып күренми иде инде.

Көннең калган өлеше авыр уйлар, борчулар белән узды. Ашы — аш, эше — эш булмады. Җиңел генә мәсьәләләрне чишә алмый изаланды.

Икенче көнне Рәсим класска иң беренче булып килеп керде. Керүгә ручканы Илһамның партасына куйды.

Озакламый бер-бер артлы классташлары да килә башлады. Ниһаять, ишектә Илһам да күренде. Ул ручкасын күргәч, балкып, елмаеп җибәрде.

— Онытып калдырганмын икән ич. Югалттым дип торам,— дип сөйләнде үзе.— Абыем бүләге...

Тик аның сүзләренә игътибар итүче генә булмады. Рәсим генә, хуҗасы кулына күчкәннән соң янә элеккечә балкып, нурланып торган ручкага карап, җиңел сулап куйды...

ХЫЯЛДАГЫ ЯШЕЛ ЯЗ

Үзе дәрестә утырса да, күңеле әллә кайларда Гөлүсәнең. Моңа укытучы Нәсимә апасы гаепле иде. Башкалар ничектер, ә кыз үпкәләде аңа. Үпкәләрлеге дә бар шул.

— «Табигать белеме» дәресен бакчада үткәрербез,— дигән иде ул. Әмма сүзендә тормады. Укучылар әзерләнеп тә килгәннәр иде югыйсә. Укытучы апалары сәбәбен әйтеп торуны да кирәк тапмады — дәресне бүген дә класста гына уздырырга булды.

— Табигатьне саклау — бөтен халык эше,— дип сөйләп китте ул.

Гөлүсә ялт итеп күтәрелеп Нәсимә апасына карады. Тик шундук карашын читкә борды. Салкын, битараф карыйлар сыман тоелды аңа укытучы апасының күзләре. Шуңамы, никадәр генә бирелеп тыңларга тырышса да, булдыра алмады. Күзге кояш нурларында балкып күренүче тәрәзә үзенә җәлеп итте. Бакчада Сәетҗан агай йөри. Мәктәпнең завхозы ул. Чү! Нишләве бу?! Кулындагы зур гына кайчы белән югарыга, яктыга омтылучы агачларның башларын, ботакларын кискәли түгелме?

Нәсимә апасыннан ишеткәннәре бар иде. Шулай итсәң, иңгә таралып үсә икән агачлар. Ә нигә биеклеккә үрмәләмәскә тиеш алар? Монысына җавап таба алмады Гөлүсә.

Сәетҗан агайның ботакларны кисүен күргәч, кыз сикереп торырга, аңа туктарга кушып, тәрәзәгә барып бәрелергә дә теләгән иде. Укытучы апасына карагач, тукталып калды. Чөнки бакчадагы күренешне Нәсимә апасы да күзәтә икән. Тәрәзә каршысына үк килеп баскан. Сөйләвен шуннан торып дәвам итте.

— Үз гомерендә кеше кимендә бер төп агач утыртырга, аны карап үстерергә тиеш...

Гөлүсәнең янә аны туктатасы:

— Ә сезнең үз агачыгыз бармы соң? — дип сорыйсы килде.

Укытучы апасының бакча ягына гамьсез генә карап торуын күргәч, бу юлы да сүз башламады. Бакча эчендә әле дә булса Сәетҗан агай йөри. Аның кулы тигән агачлар канатларын каерып ташлаган кошларны хәтерләтә.

Шул чак агачлар арасыннан песи малае күренде. Ул көзге юка кар өстендә чылбырдай эзләрен калдырып, ашыкмый-кабаланмый гына атлый иде. Елтыр

күзләрен ялтыратып як-ягына карана. Бакчадагы хәлләргә ул да битараф түгел иде, күрәсең.

Чү! Нәрсә булды аңа? Чылбыр эзен бутап, кирегә йөгерә башлады песи. Ул да түгел әллә кайдан гына озын торыклы эт килеп чыкты да сикерә-атлый песи малаена ташланды. Менә-менә эләктереп алачак, ботарлап ташлаячак.

Әмма алай булмый калды. Песи яшен тизлегендә әле Сәетҗан агайның кулы тимәгән агач башына йөгереп менеп тә китте. Озын торык исә песине тота алмавына гарьләнгән сыман һау-һаулап өрергә керешге. Ал аяклары белән агач кәүсәсен тырмап, песи янына үрләмәкче әнә.

Гөлүсә бу юлы тукталып кала алмады инде.

— Нәсимә апа... анда... эт... песи...— дип, урыныннан сикереп үк торды. Тик укытучының кырыс тавышыннан кире урынына утырырга мәҗбүр булды.

— Сине тәрәзә янындагы партадан ишек катына күчереп утыртмый булмас,— диде укытучы апасы усал гына.— Дәрес тыңлый белмисең.

Кыз башын аска иде. Укытучы апасының кошларны, җәнлекләрне сакларга кирәклеге турында әйткән сүзләре колагына керсә дә, күңеле әле дә булса мәктәп бакчасында иде аның. Ул сиздермәскә тырышып кына янә тәрәзәдән бакчага күз атты.

Песи әле дә булса куырылып агач башында утыра, эт әрле-бирле йөренеп, аның төшүен көтә иде.

Сәетҗан агай да эшеннән аерылган. Тәмәкесен төтәтеп, әлеге куыш уенының ничек тәмамлануы гамьсез генә күзәтеп тора.

Тәнәфескә чакырып, ниһаять, кыңгырау тавыш бирде. Гөлүсә аны ишетүгә йөгереп класстан чыгып китте. Бәрелә-сугыла мәктәп бакчасына килеп керде. Сәетҗан агай әле дә булса тәмәкесен суыра. Гөлүсә әле генә кисеп төшерелгән ботакны кулына ал-

ды да, абына-сөртенә, песине рәнҗеткән эт янына ашыкты. Озын торык исә, эшнең ни белән бетәсен аңлагандай, каерып ташланган койма арасыннан чыгып чапты.

Эт күздән югалуга, сыртын кабартып утырган песи агач башыннан сикереп җиргә төште дә, үзенә ярдәмгә килгән кызга борылып карый-карый, юлы белән китеп барды. Тәненә көзге салкын җил бәрелгәч, калтыранып куйды Гөлүсә. Озак басып торырга ярамый иде аңа. Ул әле кулындагы ботакка, әле Сәетҗан агайга карап алды да, бер сүз дә дәшмичә йөгерә-атлый бакчадан чыгып китте.

Ә икенче көнне, ә икенче көнне... туңудан уянып китте кыз. Бөтен тәне ут яна, кызыша. Моңа игътибар итмичә генә сикереп торган иде дә, башы әйләнеп, күз аллары караңгылана башлады, кире урынына барып ятарга мәҗбүр булды. Моны күргән әнисе телефонга барып ябышты. Врач чакыртты. Ак халатлы апа килеп күкрәген тыңлагач, тамагын ачтырып карагач, салкын тидергәнсең, дип дарулар биреп китеп барды.

...Менә икенче көн инде мәктәпкә бара алмый, урын өстендә ята Гөлүсә. Әти-әнисе көн озын эштә. Ялгызына күңелсез кызга. Җитмәсә үтереп эчәсе килә. Әнисе калдырган тәмле сулар гына сусавын баса алмады.

Кыз, онытылырга теләп, өстәл өстендәге савытта утырган агач ботакларына карады. Теге көнне Сәетҗан агай кисеп төшергән әлеге ботаклар тиздән яфрак ярырлар. Аннан кайда утыртыр икән ул аны? Кире мәктәп бакчасына утыртыргадыр бәлки? Авылда, әбиләренең йорты каршысына, бер каен утырткан иде ул. Ничек үсә икән?

Ел саен җәен авылда үткәрә Гөлүсә. Быел да шулай булды. Моннан еракта кечкенә авылда яшәүче

ягымлы әбисе шатланып каршылаган иде. Аның өчен генә дип хәстәрләп куйган нигъмәтләре белән сыйлаган иде әбисе. Салкын әйрәннең, кипкән шомыртның, әчкелтем миләшнең тәме әле дә булса тел очында тора сыман...

— Тик, кызым, сиңа чишмә суыннан гына чәй эчертә алмыйм. Хәзер без дә, сезнең шәһәрегездәге кебек, суны торбадан гына агызабыз.

— Ә ни өчен? — дигәнен сизми дә калды Гөлүсә.

— Яр буендагы чишмәбез, караучысы булмагач, күмелде шул хәзер,— диде әбисе,— элегрәк бабаң гел карап, чистартып торыр иде үзен. Ул вафат булгач, оныттылар аны...

Әбисенең әлеге сүзләрен ишеткәч, яр буена йөгереп төшкән иде кыз. Әмма никадәр генә эзләп йөрсә дә таба алмады ул чишмә урынын. Күңелсезләнеп кире кайтырга да уйлаган иде инде. Шул чак үзенә эндәшкән тавышка сискәнеп борылып карады. Инешнең теге ягында аңа карап ялан аяклы бер малай басып тора иде.

— Аягыңны кычытканга чактырып нәрсә эзлисең шулай? — дип телгә килде малай.

— Чишмәне...— диде кыз сузып кына.

Малайның гаҗәпләнүе йөзенә бәреп чыкты.

— Мондагы чишмәнең беткәненә биш былтыр ич инде,— диде ул һәм инешне ерып кыз басып торган ярга чыга башлады.

— Монда иде ул, әйдә, күрсәтим урынын...

Малай яр буенда үсеп утырган кычытканнары аралый-аралый алдан китте. Текә ярдан тәгәрәп төшкән зур гына таш янына килеп җиткәч, тукталып калды.

— Чишмәне шушы таш баскан аны,— диде.

Малай янәшәсенә килеп баскач, кыз яр өстеннән тәгәрәп төшкән таш астыннан саркып агып ятучы

көмеш тамчыларны күреп алды һәм, үзе дә сизмәстән, чишмәне әлеге бәладән коткармакчы булып, ташны читкә тәгәрәтеп чыгарырга керешге. Малай, шаярма, дигән кебек, көлеп куйды. Әмма шундук җитди чырай белән ярдәм итәргә ашыкты. Икәүләп этә торгач, ниһаять, ташны кузгаттылар. Моңа кадәр таш астыннан сыкрап кына агып яткан көмеш су күзгә күренеп таш урынын тутырды. Анда гына сыеша алмыйча, мөлдерәп, ташып чыкты, үзенә юл ярып, инешкә таба йөгерә башлады.

Чишмәнең көчле агымына карап сокланып басып торган кызның уйларын янәшәдәге ялан аяклы малай бүлде.

— Исемең ничек синең?

— Гөлүсә...

— Ә минем Айрат...

Ул чакта алар башка сүз сөйләшмәделәр дә бугай. Соңыннан, чишмә тирәсен чистартып ярга баскыч уйганда, аннан көн саен чишмәгә суга төшкәндә ныклап таныштылар, дуслаштылар Гөлүсә белән Айрат.

Чишмәнең яңадан терелүен күргәч, и сөенгән, и шатланган иде әбисе.

— Әле ярый син кайттың, кызым,— дия торган булды.

Чишмә чәе тәмле иде шул. Аның челтерәп агуын тыңларга бигрәк тә яратты кыз. Гел-гел шулай тыңлап торыр кебек иде. Санаулы көннәр тиз үтеп китте. Авылдан китәсе көнне дә чишмәгә ике-өч мәртәбә суга төшеп менде Гөлүсә.

— Ә син борчылма, моннан ары әбиеңә суны үзем кайтарып бирермен,— диде Айрат.— Чишмәне дә гел карап, чистартып торырмын. Тагын кайт син, яме?

«Сүзендә торамы икән Айрат? Нәсимә апасы кебек вәгъдәсен онытмадымы икән?»

Бу сорауга җавапны әнисе эштән кайткач тапты Гөлүсә.

— Кызым, әбиеңнән хат бар,— диде ул керә-керешкә һәм зәңгәр конвертны ачып укырга да кереште.

Хатта язылган сүзләр Гөлүсәнең күңелен күтәреп җибәрде, сусавын да баскандай булды. Әйтерсең лә туйганчы чишмә суын эчте.

Әбисе үзе турында язган-язган да: «Гөлүсәгә әйт. Айрат бик игелекле бала булды. Көн саен су кайтарып бирә. Чишмәне гел саклап-кадерләп тора. Хәзер суны күпләр шуннан ала...» дигән.

Әлеге сүзләрне ишеткәч, кыз яктырып елмайды. Савыгып киткәндәй булды. Нәсимә апасына җыелган үпкәсе дә, Сәетҗан агайга әйтә алмый калган авыр сүзләре дә онытылгандай булды. Күз алдында яр буенда чылтырап агучы чишмә, аның янында йөрүче Айрат кына торып калды. Бу минутларда хыялында яшел язларга кереп бара иде Гөлүсә.

ЮГАЛГАН ТЫНЫЧЛЫК

Шыкы-шыкы, шыкы-шыкы...

Чү! Кемдер ишек шакый түгелме соң?! Өндәме бу, төштәме?

Рәйханә ап-акка буялган мичкә аркасын терәгән дә тынып калган. Ямансу аңа. Әле кайчан гына ул, әйтерсең лә кичә генә кебек каникул көннәрен авылда — әбисе белән бабасы янында үткәрергә дип кайткан иде. Санаулы көннәр үтте дә китте. Әбисе-бабасы янында рәхәт, тыныч иде. Бүген ул урамга да чыгасы итмәде, өйдә генә утырды. Хәер, һавасы да кинәт кенә үзгәреп, салкынаеп китте шул. Урам чатларында су колонкалары туңды, торбалар шартлап ярылды.

Рәйханә бабасы белән әбисенең сөйләшүләренә колак салып утыра бирә. Ара-тирә ишегалды ягыннан Акманҗгайның өргәне ишетелеп куя.

— Сарайга — җылыга яптым,— диде бабасы үз алдына сөйләнгәндәй итеп.

Әбисе арлы-бирле йөренеп оныгының сумкасына күчтәнәчләр тутыра. Әледән-әле:

— Ничек кайтып җитәрсең инде, балам, бигрәк салкын бит,— дип сөйләнеп ала.

Менә көн узып, төнге караңгылык инде. Ятса да Рәйханәнең керфекләренә йокы кунмады. Өй бүрәнәләре чытыр-чытыр килә, электр чыбыкларында җил улый. Тыңланып ята торгач, Рәйханәнең күзләре йомылды. Тик... Тукта, кар өстен шыгыр-шыгыр китереп кем йөри анда?

Иң элек урыныннан бабасы кузгалды. Торып утны кабызды, аннан тәрәзәгә барып капланды.

— Кем бар анда? — диде ул карлыккан йокылы тавышы белән.

— Мәрхәмәтле кеше, җылынып чыгарга рөхсәт итче...

Бабасы сүзсез генә иңенә җылы тунын салды, тезе белән ишеккә төрткәләргә кереште. Бозланып каткан ишек, ниһаять, ачылды. Бабасы ишегалдына чыгып китте.

Кайарададыр, әбисе дә торып өлгергән, чәй хәстәрен күрә инә. Бераздан мич алдында гөжләп кайнарга керешкән самавар тавышына болдырда сайгак сызгырганы кушылды. Ул да түгел бер кочак салкын болыты ияртеп йорт хуҗасы һәм тагын бер ят кеше килеп керде.

— Гафу итә күрегез борчып йөрүем өчен,— диде төнге мосафир уңайсызлануын белдереп.— Соңга калынды. Район үзәгеннән кайтып барышым иде... Күрше авылдан мин, Карашайдан...

— Куй әле, олан, ниткән уңайсыз ди. Уз, әйдә, мичкә якынрак кил. Җылынырсың,— диде әби кеше.— Хәзер чәй дә кайнап чыгар.

— Атың да бик өшәнгән. Алдына печән салдым. Таңга кадәр хәл алыр,— дип кушылды бабасы.

Рәйхана җылы юрган эченнән чыкмыйча гына төнге әңгәмәгә колак салып ятты. Әлеге юлчы агай аларга чит-ят бер кеше булса да, хуҗалар кадер-хөрмәт күрсәтергә кереште аңар. Кыз шуларны күреп сокланды.

...Иртәгәсен уянып китсә, бабасы да, әбисе дә, төнге юлчы да аяк өстендә икән инде. Иң якын кешеләр сыман саубуллашып торалар. Рәйханә торып тәрәзәдән карагач күрде: җигүле ат әле булса печән чемченә, бабасы юлчыга толыбын суза...

Юлчы агай бөтен дөньяны яктыртырлык итеп елмайды да капкадан чыгып китте. Үзе китте, ә елмаюы салкын көнне җылытып җибәргәндәй булды.

Зың, зың... Шыкы-шыкы...

Нинди таныш тавыш соң бу? Тагын кабатланды, тагын...

Рәйханә күзләрен ачып җибәрде. Кайда ул? Бәй, үзләрендә, әти-әнисе өендә ич ул. Авылдан кайтканына ничә көн узды инде. Ә ул чын дөрес хәлләрне кабат төшендә күреп ята икән ич. Кыз бабасын, әбисен, төнге юлчыны хәтерләп елмаеп куйды.

«Зың, зың...» иттереп кемдер кыңгырауга басты. Рәйханәнең әтисе уянды. Әнә әнисенә эндәшә:

— Сиңа әйтәм, бар кара, кем ул анда?!

Әнисенең ухылдаган тавышы ишетелде:

— Көткән кешем юк. Торыр-торыр да китеп барыр әле...

Тагын кыңгырау зыңлады, аннан ишеккә кагылдылар.

— Эти, эти дим, эни...— дип телгә килде Рәйханә.

Алар шактый күтәреп кузгалганда инде ишектә яңадан тавыш кабатланмады... Кемнеңдер авыр адымнар белән баскычтан төшеп китүе ишетелде.

«Кем булды икән ул?» — дигән сорау Рәйханәгә тынгылык бирмәде.

Ерак авылдан килергә чыккан һәм соңарган туганнарының берсе булдымы, танышларымы, әллә башына кайгы төшкән гел белмәгән берәүме? Рәйханәнең әле генә балкып торган йөзе сүрелә башлаган иде инде. Күзләре дә моңаеп калдылар. Теге билгесез кеше Рәйханәнең тынычлыгын үзе белән алып киткән иде.

●

ЭНЕСЕНӘ УЛ АПА

АЙСЫЛУ

Әтисе Гүзәлгә курчак алып кайтты. Исеме дә бар — Айсылу исемле.

— Иптәшләрең белән бергәләп уйнарсыз,— диде әтисе.

Әй сөенде, әй шатланды соң Гүзәл! Җитен чәчле, зәңгәр күзле курчагын бер генә дә кулыннан төшермәде. Җайсызрак тотканда Айсылу:

— Ән-нә, ән-нәү-ү...— дип тавыш та бирә белә иде.

Бүген ял көне. Гүзәлне бакчага илтмәделәр. Ул сөенеп Айсылу белән уйный гына башлаган иде, урам яктан күрше кызы Рәйханәнең тавышы ишетелде.

— Гүзәл, әйдә, уйнарга!

Кыз тиз-тиз киенде дә урамга йөгерде. Айсылуның:

— Мине дә алып чык, бергә-бергә уйнарбыз,— дип ялварып карап калуын да күрмәмешкә салышты.— Әйем лә, синең белән үзем генә уйнармын,— дип ашыгып ишекне япты. Чөнки Рәйханәнең курчак белән уйнавын теләмәде ул. Урамда комнан әллә нәрсәләр, әллә нәрсәләр ясап бетерделәр. Тора-бара Гүзәл курчагы турында тәмам онытты. Өйгә кергәч кенә янә хәтеренә төшерде, йөгереп килеп Айсылуны кулына алды. Чү! Ни булган аңа? Кулга алуга:

— Ән-нәү-ү, тимәү-ү! — дигән сыман ыңгырашты да күзләрен йомды.

— Әни, әнием,— дип алгы бүлмәгә йөгереп керде Гүзәл.— Айсылу минем белән уйнарга теләми.

Әнисе сынап кызына карады.

— Әллә үпкәләттеңме үзен?

Гүзәл ни дияргә дә белмәде. Бары шунда гына

этисе әйткән сүзләрне исенә төшерде. «Иптәшләрең белән бергәләп уйнарсыз...» — дигән иде бит.

Гүзәл курчагының чәченнән йомшак кына сыйпап алды:

— Син ачуланма инде, икенче тапкыр сине дә дусларым янына алып чыгармын...— диде.

Айсылу әйтерсең лә шуны гына көтеп торган, ул зәңгәр күк йөзе төсле күзләрен ачып җибәрде.

КАШЫКЛАР

Илдар исемле энем бар минем. Бигрәкләр дә инде музыка ярата ул. Радиодан булсынмы, телевизордан булсынмы җыр, музыка яңгыраса, бөтен дөньясын оныта.

Әле дә күз алдымда: энемә биш яшь иде. Беркөнне шулай дәресләр тәмамлангач, өйгә кайтып керсәм аптырап калдым. Илдарыбыз идән уртасына утырган да... кулындагы агач кашыкларны бер-берсенә суга. Шак-шок, шак-шок... Ә аяк астында инде тәмам эштән чыккан, кителеп беткән кашыклар аунап ята.

— Менә музыка чыгарам, тыңлап кара,— дигән була үзе. Ә кашыклары бер-берсенә бәрелгән саен кителә бара иде.

Минем аптырап торуымны күргәч, энем аңлатырга кереште: «Телевизордан абыйларның кашык сугып көй чыгаруларын күрдем. Мин дә менә көй чыгарып карыйм әле...»— диде дә тагын үз эшенә кереште. Шак-шок, шак-шок...

Мин исә: «Ишкәнсең икән ишәк чумарын»,— дип кенә әйтә алдым.

Менә шул. Ә сез бәлки шуннан ни булган дип сорарсыз? Ни булсын. Энем әле дә музыка ярата. Инде үсеп җитте. Өченче класста укый. Бирелеп баянда

уйнарга өйрәнә. Кашыклар вакыйгасын еш кына көлеп искә алабыз. Мондый вакытларда энем җитди генә әйтеп куя:

— Үскәч барыбер музыкант булам,— ди.

Булыр да, ышанам мин аңа.

БЕРЕНЧЕ ХАТ

Ләйсән җәй саен Карамалыга кунакка кайта иде. Быелгы җәйне исә ул аеруча түземсезлек белән көтеп алды, өзелеп-өзелеп әбисен, бабасын сагынды.

— Авылга кайчан кайтабыз инде? — дип гел-гел кабатлап торды Ләйсән.

— Болыннар чәчәккә төренсен әле, кызым,— дип юаттылар аны әнисе белән әтисе.

Ниһаять, көткән көн килеп җитте. Әтисе:

— Кызым, иртәгә бакчадагы иптәшләрең белән саубуллашып кайт, яме. Авылга китәбез, мин билетлар да алдым инде,— диде.

...Авыл Ләйсәнне бик сагынып көткән икән. Матур итеп, пөхтә итеп киенгән оныкларын күргәч, әбисе белән бабасы әй сөенделәр, әй шатландылар! Алар, кызыбызга дип, әллә нинди сый-хөрмәтләр әзерләп торганнар. Чикләвек дисеңме, мәтрүшкәле чәйме, каймак, коймакмы... Өстәлгә ниләр генә куелмады.

Ләйсән әбисенә кәтү куарга, малларны каршы алырга булышты, каз бәбкәләрен саклашты, бабасына яшелчә үстереште. Күрше кызлары, малайлары аны басуга, урманга алып бардылар. Бергәләп су коенулар, җиләккә йөрүләр бигрәкләр дә күңелле иде.

Кояшлы, чәчәкле-җиләкле җәй гел бетмәс кебек тоелды Ләйсәнгә. Ә китәр көн сиздермичә генә килде дә җитте.

— Менә мәктәпкә генә йөри башлыйм әле,— диде кыз саубуллашканда күзләрен бер әбисенә, бер бабасына төбәп.— Мин сезгә хат язып салырмын.

— Язарсың, балам, язарсың,— диделәр әбисе белән бабасы.— Гел «дүртле», «бишле» генә алып укы, яме,— дип тә әйттеләр.

...Мәктәптә көннәр тиз уза икән. Беренче чирек тә узып китте. Икенчесе дә йөгерә генә. Күп кенә хәрефләрне таныргга, саный, куша, ала белергә өйрәнделәр инде беренчеләр. Ләйсән берничә дәфтәрне язып тутырырга да өлгерде.

Беркөнне мәктәптән кайтып кергән Ләйсәнгә әнисе:

— Кызым, әбиләреңнән хат бар. «Оныгыбыз ничек укый?» — дигәннәр. «Безгә кайчан хат яза башлый инде?» — дип сораганнар,— диде.

Ләйсән авылдан килгән, бабасының кытыршы куллары белән язылган хатны әйләндереп-әйләндереп карады. Битләренә куеп торды. Укырга да теләгән иде, араларында әле аңа таныш булмаган хәрефләр чыккач, тукталып калды.

«Их! Нигә көнгә берәр генә хәреф өйрәтәләр икән?» — дип авыр сулап куйды ул. Шулай беравз өзгәләнеп басып торгач, кызның йөзе кинәт яктырып китте. Ул кабаланып сумкасын ачты, папкадан язу дәфтәрен тартып чыгарды, ашыкмый гына аның битләрен актара башлады. Менә бу биттә горур гына «бишле» билгесе басып тора. Монысында — «дүртле», тагын «бишле», тагын...

— Әни, әнием,— диде Ләйсән.— Бу хакта җавапны үзем язам, яме. Менә шушы дәфтәремне җибәрәм аларга.

Кичен Ләйсән зур гына конвертка теге дәфтәрне салды да пөхтәләп ябыштырды. Аннары әнисе аны почтага илтеп тапшырды. Ләйсәннең беренче хаты авылга юл алды...

КЕЧКЕНӘ РИНАТ

Ринатның әнисе китапханәче булып эшли. Еш кына әнисе белән кечкенә Ринат та китапханәгә бара. Ул анда китаплар карый. Әнисе аңа әкиятләр укый. Әкият тыңларга бик ярата шул малай.

— Үскәч, дәү булгач, мин дә сиңа укырмын, энием, яме, ул чакта син тыңлап кына утырырсың! — ди.

— Ярар, улым,— ди әнисе, улының маңгаеннан үбеп.

Ринат янә китаплар карый башлый. Бер дә ертмый ул аларны. Бу хакта — китапны ертырга ярамаганны — дусларына да әйтә.

— Китапны ертмагыз! — ди.

Кайберәүләр кебек түгел шул ул, кечкенә булса да китапны ертырга ярамаганын, синнән соң башкаларның да аны укыйсын белә ул.

МИЛӘШ НИГӘ АЧЫ?

Тагын яз килде. Мин кулыма көрәк алдым да бакчага чыктым. Бабам күптән шунда икән инде. Саклык белән генә миләш төбен йомшартып маташа иде ул.

— Бабай, әйдә, миләш төбен йомшартканчы, алмагачлар тирәсен казыйк! — дидем мин.

Бабай башын аска ия төште. Шактый вакыт торганнан соң гына сүз башлады.

— Улым, юкка алай дисең. Тыңла әле менә, мин сиңа бер әкият сөйлим.— Һәм ул сөйләп китте.—...Борын-борын заманда абыйлы-сеңелле ике туган яшәгән ди. Авырлык өстенә авырлык, кайгы өстенә кай-



гы килгән. Бер заман бер патша сугыш ачкан. Типсә тимер өзәрлек егетләрне яуга куганнар. Кызның абыйсын да сугышка алганнар. Мескен кыз кайгысыннан әй елый икән...

— Кайтмасам, бәхил бул,— дигән абыйсы.— Мин утырткан миләшләрне төсем итеп карарсың...

Һәм ул өй алдына пар миләш утыртып калдырган.

Абыйсын бик озак көткән кыз. Аның белән бергә кадерле абыйларын миләшләр дә сагынып көткәннәр. Киткән юлына карау өчен һаман югарыга үрләгәннәр. Ә егет кайтмаган да кайтмаган. Хәзер инде сеңлесе көн-төн елый икән.

Миләшләр апаларының кайгысын уртаклашырга сүз куешканнар. Аның ачы кайгысын үзләренә кабул иткәннәр, күз яшен сеңдерә барганнар...

Бабам, авыр көрсенеп, сүзен тәгәлләде. Мин аның нәрсә әйтергә теләвен аңладым. Сүзләремнән уңайсызланып, иләп кенә миләш төбен йомшартырга керештем...

ЭНЕСЕНӘ УЛ АПА

Дүртенче класста гына укыса да Гүзәл инде апа кеше. Аның үзе шаян, үзе шук Илнур исемле энесе бар. Түгәрәк йөзле, тып-тып басып йөрүче шул малай яратып, якын итеп «Гүзәл апа» дип дәшә аңар.

Апалы-энеле ике туган бик тату, бик дус яшиләр. Һәркөнне иртән эниләре белән берсе — мәктәпкә, икенчесе — бакчага бара. Күп тә түгел, аз да түгел — көн озынына гына аерылышып торалар югыйсә. Әмма сагынышырга да өлгерәләр. Өйгә кайткач, Гүзәле Илнурга мәктәптә күргәннәрен, нинди дәресләр булганын, нинди билгеләр алганын сөйләсә, энесе апасына бакчада үзе уйнаган аю малайлары, төлке

кызлары турында тәтелди. Аларның әллә нинди кызык хәлләр хакында сөйләшүләрен әйтеп кенә бетерерлекмени соң?! Еш кына энесен бакчадан Гүзәл үзе кереп ала. Кайчак әнисе белән әтисе я эштә тоткарлана, я кибет аркылы узасы була.

Бүген дә Илнурны бакчадан апасы алып кайтырга булды. Үзе кебек кечкенә малайлар, кызлар белән уйнап утырган малай апасын күргәч йөгереп аның янына килде.

Ниһаять, апасы ярдәм итешә торгач, Илнур киенеп тә өлгерде. Әйтерсең лә катлы-катлы кәбестә булды. Тик сез болай дигән өчен көләргә ашыкмагыз әле, яме! Урамда кыш бит, салкын. Кечкенәләргә туңарга ярамый. Туңдың исә авырыйсың. Авырыйсың икән бакчага бара алмыйсың. Бакчага бармыйсың икән, әниең өйдә утырырга тиеш. Ә әниләргә эштән калырга ярамый.

Энесен җитәкләп Гүзәл урамга чыкты. Акрын гына өйләренә таба атлап киттеләр.

Тик ни хикмәт бу! Ике-өч адым атлый да таеп егыла Илнур, ике-өч атлый да егыла. Их, юлы бозлавык шул. Болай кайту ошамады малайга. Егылган җиреннән апасы ярдәмендә торып басты да туктап калды. Атларга куркып тора. Башка егыласы килми, күрәсең. Ике кулын күтәрде дә апасына үрелде.

— Күтәр мине...— ди.

Гүзәл аңлатып та карый: «Авыр ич син! Иплэп кенә кайтырбыз»,— ди.

Юк, файдасы тими. Алдагы юлга карап ала да малай, тагын егыласын белеп, шул ук сүзне кабатлый.

— Күтәр!.

— Ә бергә егылсак... тагы да катырак авыртыр бит, икебез дә имгәнербез...

— Юк,— дип үзсүзләнә энесе,— син мине күтәр,

ә мин сине егылмас өчен муеныңнан кочаклап барырмын...

Нишләсен Гүзәл, энесе белән килешергә туры килде аңа. Ул малайны кулларына алды, Илнур да сүзендә торды — чытырдатып апасын кочаклады.

Акрын гына кузгалып киттеләр. Күр әле син аларны, аяк асты тайгак булса да егылмыйлар бит! Хәер, нигә егылсыннар. Апасы таеп китмәсен өчен энесе дә тырыша ич.

ҺӘЙКӘЛ

Һәркөнне шулай. Иртә белән дә, мәктәптән кайтып килешли дә юлым бер үк җирдән — тын бакча аша уза. Бакча уртасында һәйкәл басып тора. Өч ир-егет кулларына Җир шарын алганнар да аны югары күтәргәннәр.

Соңгы вакытларда Җир-әнкәбезнең төрле почмакларыннан сискәндергеч хәбәрләр килә. Кулларын канга буяган башкисәрләр җиребезне юкка чыгарырга теләп үлем кораллары ясыйлар. Җир сылуның йөрәгенә хәнҗәр кадарга, сулышын буарга тырышалар. Күрәсең, андыйларга җиребез гади бер туп шикелле генә тоела. Алар аны пычрак аяклары белән таптарга, типкәләргә җыеналар.

Җиребезнең киләчәге өчен, аның тәне сугыш утларында янмасын өчен төрле төбәкләрдән төрле телләрдә авазлар ишетелә. Миллионнар «Тынычлык», «Дуслык», «Туганлык» дип тавыш бирәләр.

Җиребезне, аның язмышын битараф булучылардан аралап, көчле куллар югары күтәрелә.

Сабыйлар уйный, әти-әниләр ял итә торган тын бакча уртасында калыккан әлеге һәйкәл туган җиребезне күз карасыдай сакларга — яхшы укырга, тырышып эшләргә чакыра.

Имәндә икән чикләвек



ОНЫГЫ ӘБИСЕН НИЧЕК КУНАК ИТТЕ...

Сагынган, бигрәкләр дә сагынган иде Хөснижамал әби оныгы Нәсихне. Ничек инде сагынмасын, төпчек улы Гаделрәшитенең малае ла ул. Бердәнберләре.

«Күрмәгәнемә кайчан бит үзен. Барам әле бәләкәй Габдерәшитем янына. Туйганчы үчтеки-үчтеки итеп сөям әле...» — дип сөйләнеп йөри торгач байтак вакыт үтте. Ниһаять, теләгенә иреште. Зур калада яшәүче малаеның ишеген ачтырып эчкә узды да, төенчекләрен аяк астына куя-куя, әлеге дә баягы шул ук җырын көйләргә кереште:

— Кая минем бәләкәй улым, кая минем Нәсих бәбкәм?

Вакыт табып килеп чыгасы иткән әниләренә карап елмаючы улы белән килененә әллә ни игътибар да итмәде хәтта.

Тавыш-тын ишетелмәгәч, улыма ул-бу булмагандыр бит, дип борчыла ук башлаган карчык эчкәрге бүлмәләрнең берсеннән машина тавышы чыгарып уйнаучы оныгының дөбер-шатыр чабуларга керешүен ишетеп җанланды. Шөкер, исән-сау икән. Ул да булмады, башы-күзе җимерелгән Нәсих җәлт кенә үзе дә килеп чыкты.

— Кил әле монда, улым, кил әле үзеңне пәп итә-итә тупылдатып алыйм әле,— дип, әби кеше кочагын җәйде.

Тик оныгы аның куенына атылырга ашыкмады. Түп-түгәрәк йөзенә. «Бу кем инде тагын?» — дигән

кыяфәт чыгарып, астан гына карап тора башлады. Әбисе сүзен янә кабатлагач кына телгә килде. Баллы ризыкны күп итеп ашаудан бозылып сирәгәйгән тешләре арасыннан сызгыртып сүзләр тезде:

— Кирәк булса, үзең кил...

Әбисе аның сүзләрен әллә ишетте, әллә юк, игътибар итмәде.

— Ай минем багалмам, күрче ничек дәү булып үскән бит ул,— дип сөйләнә-сөйләнә оныгы янына атлады.

Чыннан да кай арада үскән диген Нәсих. Буйга гына түгел, туп кебек иңгә дә түгәрәкләнгән. Әнә ул әбисе килеп җитәм, килеп җитәм дә кочагыма алам дигән мәлдә генә бауга тагылган зурдай калай машинасын дөбер-шатыр сөйрәп җитез генә икенче бүлмәгә таба йөгереп китте. Бераздан туктап, әбисенә телен чыгарып күрсәтте дә: «Тота алмадың бит»,— дип үчекләгәндәй, кеткелди-кеткелди көлергә керешге. Янә дә йөгереп китмәкче иде, ишек төбендә әбисе алып килгән төенчекләрне күреп, алар янына килеп басты.

— Миңамы? Күчтәнәчме? — дип, инде үзе үк сырпаланырга керешге. Хәтта Хөсниҗамал әбисе сөйгәндә дә карышмады. Күзләрен елт-елт китереп төенчекләрне кармаларга тотынды.

— Бигрәкләр дә Габделрәшит улыма охшагансың шул, кечкенә чагында ул да нәкъ синең кебек тиктормас иде,— дип сөйләнде әби кеше.

Ә берничә минуттан малай кухняга чыккан һәм әбисенең алдына ук менеп кунаклаган көйгә бик тәмләп коймактыр, бавырсактыр, кош теледер кебек авыл күчтәнәчләре белән сыйланып утыра иде.

Хөсниҗамал әби исә сөенеченнән гел сөйләнә торды:

— Баламның баласы балдан да татлырак шул,— дип, балавыз да сыгып алды.

Инде бу кадәр дә сыйлангач, тәмам үз итте Нәсих әбисен.

...Иртәгесен этисе дә, әнисе дә икәүләп малайны бакчага барырга күндерергә тотындылар. Тик кая ул, малай юхаланып әбисенең муенына сарылды, чут-чут итеп җыерчыклы бит алмаларыннан үпте һәм тәки бу көнен өйдә үткәрергә ризалык алды.

Кичә оныгының нинди һөнәрләргә ия булганлыгын белеп бетермәгән икән әбисе. Малай иң элек бөтен уенчыкларын бүлмәләр буйлап таратып ташлады. Хөснижамал әби аңа карап янә төпчек улының балачагын хәтеренә төшерде. Ул да йорттагы бөтен нәрсәне шулай таратырга мачтр иде. Кире җыйнап алулары үлем белән бер булыр иде. Уенчыклар белән мәйхәнә килгәч, Нәсих туп тибәргә кереште. Аздан гына тәрәзәне челпәрәмә китермәде, бәхеткә бу уены өстәлдәге чәчәк савытын идәнгә тәгәрәтеп төшерү һәм бер читен китү белән тәмамланды. Нишләсен әби: «Иплэп уйна, улым, иплэбрэк...» — дип кисәтеп караса да, игә килмәгән оныгы турында: «Бигрэкләр дә улымның үзенә охшаган шул, ул да күпме тәрәзәнең башына җитте бит заманында»,— дип уйлану белән чикләнергә мәҗбүр булды.

Тора-бара туп онытылды. Берара малай суга төшеп чумгандай юк булды. Караваг астында яткан икән. Аннан кәшәкә таяк һәм анысына ияртеп алка сөйрәп чыкты. Әбисенең: «Бу нәмәстәләр белән бозда гына уйныйлар бит...»— дигәненә исе дә китмәде. Карчыкны ай-ваена карамыйча ике урындык арасына — «капка»га бастырды, шалт та шолт аңа алка очырта башлады. Алка әбинең камыт аягы арасыннан очып үткән саен дөнья җимереп:

— Ур-ра! Го-ол-л!! — дип кычкырды.

Малай чираттагы һөҗүме вакытында әбисенең тез капкачына кәшәкә белән кундырды. Бу юлы да

әбисе ачуланып сүз әйтмәде, яраткан оныгы булгангадыр инде.

Бераз хәл алгач, аягының авыртуы басыла төшүен сизгәч, малай әбисен урамга чыгарга әйдәкли башлады.

— Әйдә, балам, йөреп керик алайса.

Әмма урамга тиз генә чыгып китәргә язмаган икән. Нәсих кайдандыр тунын сөйрәп, шарыфын, бияләен, итеген табып китереп әбисе алдына өяргә кереште.

— Киендер мине,— диде.

Әбисе: «Һай, улым, мин сине зур үскән бу, дигән идем. Ә син киенә дә белмисең икән»,— дип оялтып караган иде дә, барып чыкмады.

— Киенә белмәсәм, чишенә беләм мин,— дип кенә аның авызын томалап куйды малай.

Җитәкләшеп урамга чыктылар. Шулай матур итеп кенә йөрерләр сыман иде. Өч-дүрт адым атларга да өлгермәделәр, малай карга бата-чума якындагы шугалакка таба элдерде. Ул әбисенең:

— Иплэп, улым, имгәнә күрмә, балам,— дип кычкырып калуына да колак салмады. ,Өстен-башын юешләтеп кире әйләнеп килгәнче тагын байтак вакыт узды.

Борынын мышкылдатып, итек астын бозга катырып килгән Нәсих мут елмаеп әбисенең бер алдына, бер артына чыга башлады.

— Әйдә, әбекәй, сиңа үзебезнең кибетләрне күрсәтәм,— дип юхаланырга кереште.

Монысына да күнде әби кеше. Оныгы сөт, ипи кибетләрен йөгертеп кенә узды. Ишекләре мул итеп ачып куелган ниндидер кибетнең текә баскычыннан йөгереп менеп китте дә керүче-чыгучылар арасында буталып күздән язды. «Адашып китмәгәе...»— дип

пошаманга калган әби үзе дә еш-еш сулап аның артыннан ашыкты. Ай-һай зур иде әлеге кибет дигәннәре. Әти-әниләренә сарылган малайлар-кызлар рәтләр буйлап чабулый. Ни генә юк биредә. Уенчык машиналар, танклар, пушкалар дисеңме, барысы да: «Мине ал да мине ал»,— дип кызыктыра. Киштә башларына менеп утырган аю малайлары, төлке кызлары, куян балалары үзләренә кул сузарга кушып күз кыса...

Инде кай тарафтан табырга оланны, дип аптыраашта басып торган әби якында гына Нәсихнең чепелдек тавышын ишетеп, сискәнеп куйды.

— Әйдә, әби, тизрәк инде...

Баштарак танымый торды Хөснижамал карчык оныгын. Бүреге бер якка янтайган, изүләре ачылган... Иңендә автомат, ике кулында тагын нindiдер ялтыравыклы нәрсәләр.

— Әйдә, әби, әйдә... Түлә дә акчаңны...

Хөснижамал карчык бу сүзләрдән авып китә язды...

Балалар янында байтак торырмын әле, дип кунакка килгән Хөснижамал әби түзмәде, бер-ике көннән: «Өйдә эшләрем өелеп калды»,— дип сөйләнә башлады. Улы Габделрәшитнең бер әнисенә, бер улына карап хәйләкәр елмаюын күрмәмешкә салышты. Кече улына бик тә охшаган онысын әти-әнисенең үзләренә калдырып, авылына кайтып китте.

ЙОКЫ ЧҮЛМӘГЕ

— Мәктәбеңә соңга каласың бит, тор инде,— дигән тавышка күзләрен ачты Хәмит. Әмма кузгалырга ашыкмады, икенче ягына әйләнеп ятты. Көн саен шушы хәл. Иртә белән урыныннан кузгала алмый

газаплана. Сәбәбен белән анысы үзе. Соң ятканнан шулай. Телевизор каршында үткәрә кичен. Әнисенең мең дә бер тапкыр искәрткәне бар инде. Тыңламый.

— Ичмасам, кулыңа китап тот, я булмаса башка шөгыль тап,— ди әнисе гел. Улының исе китми генә утыруын күргәч, тагы да ныграк битәрләргә керешә.— Әнә Инсафтан үрнәк алыр идең. Укуы да яхшы, кул арасына да керә. Фото түгәрәккә йөреп, рәсем төшерергә дә өйрәнгән. Уйнарга өйрәнәм дигәч, этиең нинди матур гармун алып кайтты үзеңә. Ә син...

Әнисе хаклы. Гармуны кайчаннан бирле тузан җыеп ята. Бер-ике көй өйрәнгән иде анысы. Тик алары да онытылып бетте инде. Ә Инсафка чыннан да фото җене кагылган. Кайчан карама, иңендә фотоаппарат булыр. Әйдә, сине дә өйрәтәм дип әйткәне дә бар Хәмиткә. Тик ул гына вакыт тапмады. Аннан соң, өнәп тә бетерми ул Инсафны. Бигрәк тә стена газетасы редакторы булып алгач. Мәктәптәге тәртипсезлекләрне, начар укучыларны фотога төшереп газетага чыгарды. Бер-ике мәртәбә Хәмитне дә әләктерде.

Әнисенең тавышы кабат ишетелде. Тавышы усал яңгырады бу юлы. Ярар, торырга кирәк. Киереләсузыла кузгалды Хәмит. Ашык-пошык юынды да иркенләп өстәл янына утырды (монысын беркайчан да онытмый ул). Аннан сумкасын күтәреп ишегалдына чыкты. Ничек онытылган диген, шунда гына исенә төште. Беренче дәресләре бүген дә арифметика бит. Бәй, өй эшен эшләргә уена да килмәгән ич. Юкса кичә генә укытучы апалары әйтеп җибәргән иде.

— Кара аны, Хәкимов, бүгенгә «икеле» куймый торам үзеңә. Чөнки болай да җитәрлек алар синең. Иртәгә әзерләнеп килгән бул,— диде.

Әлегә сүзләр исенә төшкәч, куырылып килде малай. Аларны кабат ишетмәс өчен, юрган астына кереп качардай булды. Тик мөмкин түгел иде бу эш. Өйгә әйләнеп керү турында уйларга да ярамый. Әнисе болай да: «Соңга каласың»,— дип, этеп-төртеп дигәндәй, чыгарып җибәрде. Мәктәпкә дә аягы тартмый. Нишләргә?

Шул чак күзе Инсафлар белән ике арадагы тыкырыкка куелган печән кибәненә төште. «Куыш ясарга да керергә дә утырырга шунда. «Икеле» арттырып тормыйм әле. Авырдым диярмен».

Аяклары Хәмитне кибәнгә таба әйдәде. «Йокым да туймаган иде әле, вәт шәп булды!» — дип уйлады малай. Үзенең тапкырлыгына сөенеп, хуш исле печән артына аркасы белән сөялеп утырды. Озакламый изерәп йокыга да китте. Нишләмәк кирәк, йокысы килгәч йокласын, матур төшләр күрсен әйдә...

Мәктәпкә барырга чыккан Инсаф аны күреп алган иде. Печән кибәне янында сумкасы аунап яткан, ә үзе изерәп йокыга талган классташын сурәткә алды да, аяк очларына гына басып, яныннан китеп барды...

ИМӘНДӘ ИКӘН ЧИКЛӘВЕК!..

Сез ничектер, ә менә Самат яратмый ботаниканы. Яратмый! Дәрестә утырса да, күңеле белән әллә кайларда. «Үсемлекләр, агачлар турында мин күз йомып та сөйли алам»,— ди Самат.

Бик яхшы... Ләкин узган атнада булган вакыйга аның бу сүзләрен юкка чыгарды бит әле. Ник дисәң...

Хәер, баштан ук сөйлим. Мин энем белән каен агачы утыртып ята идем. Самат килде дә: «Их, сез,

каен утыртканчы, бакчагызга берәр җиләк-җимеш агачы утыртсагыз ак сакаллы карт булыр идегез»,— дип, безне эштән бүлдерде. «Менә минекен барып карагыз, алмагач утырттым. Күп тә үтмәс, алма да бирә башлар...»

Без Саматка ияреп алмагачны карарга киттек. Тик баруга аптырашта калдык. Саматның алмагач дигәне су буенда үсә торган зирек агачы гына иде. Менә сиңа ботаника! Болай булгач, имәндә икән чикләвек!..

БЕРЕНЧЕЛӘР

Үлчәп, санап карасак, аптырашта калдык. Егерме кило тотылган кәгазь җыярга тиеш идек. Алты кило җитми.

— Ычкынды болай булгач беренче урын! — дип урыныннан сикереп торды минем белән бер партада утырган Акмал.— Юкка тырышканбыз...

Чыннан да, шушы кәгазь аркасында барысы да чәлпәрәмә киләчәк. Югыйсә өлгереш буенча да сынатмыйбыз. Әби-бабайларга да булышкалый безнең отряд... Каян алырга инде шул алты кило кәгазьне?

Кинәт класс ишеге ачылып китте — җыештыручы Хәния апа килеп керде. Ул безнең борчулы йөзләребезгә бераз карап торды да:

— Ни булды сезгә? — диде йомшак тавыш белән.

— Кәгазь җыярга кирәк. Табып булмый.

Тукта, нишләп соң әле Хәния апаның йөзе яктырып китте? Әнә парталар арасыннан йөренә. Туктады. Кара такта янына барып басты.

— Һәркайсыгыз парта астын карасын әле,— диде ул. Үзе серле елмая.

Күзебез шар булды — парта асларыбыз тулы чүпчар иде.

— Хәзер идәнгә карагыз инде,— диде Хәния апа.

— У-у-у! Идән дә гел кәгазь генә. Борчак пешә болай булгач!

Без шау-гөр килгән арада Хәния апа зур гына бер капчык та күтәреп кергән.

— Менә монда да кәгазь. Сезнең класстан җыйдым,— ди.

— Тукта, соң болай булгач... болай булгач без бит, без хәтта беренче урынны алабыз!

— Ур-р-р-а! Без беренче!!!

ИҖАТ ГАЗАБЫ

Көннәрдән бер көнне җиденче класс укучысы Сәлмән Бикмуллинның күңелендә мәктәпнең стена газетасына мәкалә язу теләге туды. «Мин кемнән ким? Башкалар яза ич!» — дип уйлады ул.

Тик нәрсә турында язарга? Уку турында, әби-бабайларга булышу хакында күп язылды инде. Нигә кабатларга? Эт белән мәче «дуслыгы» турында да укыганы бар.

Мәкалә язу теләге аның тынычлыгын тәмам алды. Өйгә кайтса да, мәктәпкә барса да шул хакта гына уйлый, иҗат газабында яна башлады.

Менә бүген дә, Бикмуллин үзе физика дәресендә утыра, ә күңеле язылачак мәкаләгә тема эзли. Сәлмәннең уйчан күзләре классташларына текәлгән. Әнә күрше партада Сәгыйтьне күр әле син! Үзе укытучы сөйләгәнне тыңлаган булып кылана. Зөфәр Гыймаевич читкә борылган арада кабалана-кабалана дәфтәренә нидер яза! Әһә! Тез башына партадашы Гөлфиянең дәфтәрен куйган да, өй эшен күчерә икән...

Әлфия белән Сания тын да алмый, Салих белән Өлфәт тә бирелеп дәрес тыңлыйлар. Керфекләрен дә какмыйлар хәтта. Укытучының сыңар сүзен дә читкә җибәрмәскә тырышалар.

Икенче партада утыручы «Профессор» кушаматлы Сәгъдия бүген дә үз эше белән мәшгуль — күзлеген борын очына ук төшереп куйган да китап укый.

«Аларга рәхәт, мәкаләгә тема эзләп интегәсе юк»,— дип уйлый Сәлмән.

Һич көтмәгәндә янәшәдә утыручы Галия терсәге белән Сәлмәнгә төртте.

— Әйдә, булыш әле...

Крассворд чишә икән. Сәлмән борынын җыерды. Уйларга комачаулама әле, янәсе. Шул вакыт укытучы сөйләүдән туктап калды.

Тез башындагы дәфтәрләр, кызыклы китаплар, кроссвордлы журналлар — тагын әллә ниләр өреп очыргандай юкка чыкты.

Зөфәр Гыймаевич Сәгыйтькә, Сәгъдиягә, тагын кемнәргәдер кисәтү ясап узды. Тегеләр гаепле башларын иделәр. Тик, укытучы яңадан сөйли башлауга, каядыр яшерелгән дәфтәрләр янә берәм-берәм чыгып, тез өсләренә кунакладылар, кызыклы китапларның битләре ачылды, кроссвордлар шакмакларына сүзләр тезелеп китте.

Тик Сәлмән Бикмуллин гына язылачак мәкаләсенә һаман тема таба алмый интегә иде әле...

БЕЛСЕННӘР КЕМЛЕГЕМНЕ

Бу ни хәл: ярыш йомгакларын күрсәтүче исемлектә безнең отряд тагын койрыкта сөйрәлә. Оятымнан җир тишегенә керерлек булдым. Ярый әле бер мин генә түгел икән җаны сызлаган кеше. Класс җитәк-

чебез Сания апаның да йөзе кара көйгән. Дәрес тәмамлануга хурлыктан өйгә сыптырырбыз дип кенә тора идек, укытучыбыз юлыбызга аркылы төшеп:

— Я әйтегез, киләчәктә нишләргә уйлыйсыз? — диде. Әйтерсең кыңгырау шалтыравын ишек артында көтеп кенә торган. Теләр-теләмәс кире борылып, урыннарыбызга таралышырга мәҗбүр булдык.

Укытучыбыз кара такта алдында әрле-бирле йөренә. Ә безнең башлар иелгән. Авызыбызга су каптыкмыни. Әлеге сорауга җавап бирергә беркем дә ашыкмый. Каш астыннан гына бер-беребезгә карап алдык. Башкалар ни уйлыйдыр, минем торып басасым, классны артка сөйрәүчеләрнең, тәртипсезләрнең тетмәләрен тетеп саласым килә. Тик шелләтә. Чөнки соңыннан үземнең тетмәне тетәселәрен беләм.

Укытучы апабыз янә телгә килде.

— Ягез, я! Сөйләгез, нишләргә безгә?!

Башлар тагын да түбәнрәк иелде. Нишләргә?! Түзмәдем торып басарга булдым. Сизеп торам шул чак — классташлар: «Өнебезме бу, төшебезме?» — дип карыйлар миңа. Чөнки моңарчы урынымнан трактор белән дә кузгатып булмасын беләләр иде. Җитмәсә, «Йомыкый» дигән яман атым да бар иде. Шулаен шулай анысы. Ярыйсы гына укысам да, кыюсыз идем. Менә хәзер күрсәтим әле үземнең кем икәнемне. Соң булса да уң булсын диләр бит.

— Отрядыбызның артка сөйрәлүенә сәбәпләр күп ул,— дип башладым сүземне. Беренче тапкыр сүз алгангадыр инде, тавышым дулкынланып чыкты.— Ярыш йомгакларын карагач, күргәнсездер. Өлгереш буенча мәктәптә иң арта без. «Икеле»ләр санын арттыручылар кемнәр дисезме?!

Әһә! Классташларның күзләре очкынлана төште. Моңа кадәр белми яшәлгән икән. Рәхәт икән ул барысын да үзеңнең авызыңа каратып торулары. Каян килгәндер кыюлык, эре-эре атлап, класс алдына

ук чыгып бастым. Укытучы апа кебек әрле-бирле йөренеп, сүземне дәвам иттердем.

— Отрядыбызны артка сөйрәүчеләр барыбызга да мәгълүм. Әнә безнең арада утыра алар.— Мин бармагым белән почмак якта утыручы Рәшиткә төртеп күрсәттем. Шуны гына көтеп торганнар диярсең, дәррәү башларын Рәшит ягына бордылар. Ә ул... ул бу хәлне көтмәгән иде, билгеле. Җитен чәчле, сипкелле малаебыз кып-кызыл булды. Моңа кадәр һәммәбезне куркытып торган зуп-зур йодрыклары парта астына шуып төшеп китте.

Классташларның үземә җәлләп карап алуларын да сизеп өлгердем. «Үз башыңа кыланасың, малай. Бөтерә, ашый, чәйнәп ташлый ич үзеңне Рәшит...» шулай дип уйласа уйларлар, ә мин тагы да дәртләнеберәк сөйләп киттем. Янәшәдә укытучы апа басып торгач рәхәт икән ул.

— Рәшитнең өй эшләрен эшләп килгәнен күргәнегез бармы? Ә-ә, эндәшмисезме?! Чөнки булганы юк андый хәлнең. Урамда тырай тибеп йөрергә таба ул вакытны, ә дәрес хәзерләргә — юк. Шуңа күрә дә «икеле»ләре буа буарлык аның. Югыйсә укытучы апабыз күпме әйтә аңа, эти-әнисен чакырып та сөйләшә. Файдасы гына күренми...

Рәшит белән алыш-бирешне бетердем. Хәзер кемгә тотыныйм икән дип кенә торганда күзем Локманга төште. Шул ич инде һәрвакыт дәрескә соңарып килүче. Классны артка сөйрәүче.

— Син, Локман дус,— дим,— кайчан кеше рәтенә керәсең инде, ә?! Нигә һәрчак дәрескә соңга калып киләсең син? Җитмәсә еш кына китап-дәфтәрләреңне дә онытып калдырасың...

Локман сөзгәк сыер шикелле бүртенде. Тик дөрес сүзгә җавап кына бирә алмады.

Ярышка йомгак ясаганда барысын да искә алды-

лар. Укуны да, тәртипне дә башкасын да... Урынымнан кузгалганмын икән инде, күңелдәгенең бөтенесен дә әйтеп бетерергә кирәк. Шулай эшләдем дә.

— Сиңа, мәсәлән, Фәридә, тәртибеңне яхшыртырга кирәк. Иң элек дәрес вакытында әдәби китаплар укуыңны туктат син, дәрескә күбрәк игътибар итсәң укуың да яхшырыр. Сезгә исә, Нәҗибә белән Кәбирә, сүзегездә торырга өйрәнергә вакыт. Ялгыз әбиебез Фәрдәнә түтигә шефлык итәбез дип вәгъдә бирдегез. Тик әлегә кадәр кыл да кыймылдатканыгыз юк...

Үзем сөйлим, үзем классташларны күздән кичерәм. Рәшит төйнәлгән йодрыкларын парта астыннан тартып чыгарган. Аларны кая куярга да белми утыра. Локманның да тешләре кысылган. Нәҗибә белән Кәбирә дә сикереп торырга — миңа ташланырга әзер булып утыралар. Утырмагайлары тагын. Әле тегенең, әле моның юньсезлекләрен күрсәтә-күрсәтә сөйләвемне дәвам иттем. «Менә шундый кимчелекләрдән арынсак, классыбыз алга китәчәк»,— дип тә өстәдем. Бер караганда дөрес сөйлим инде үзем. Укытучы апаның да, классташларның да йөзеннән шуны чамалап алдым. Тик, ни хикмәттер, сүзем кимегән саен шикләнүем арта барды бит. «Соңыннан нәрсә булыр? Рәшит белән Локман нәрсә диярләр?»

Һай! Нигә исем китә соң әле. Укытучы апабыз кайтырга рөхсәт кенә бирсен. Иң беренче булып класстан йөгереп чыгып китәчәкмен. Ә өебез якында гына. Куып тотып карасыннар. Иртәгә исә башка мәктәпкә барам мин укырга. Әтигә яңа фатир бирделәр. Иртәгә күченәбез без...

●

ЭЧТӘЛЕК

Кайнар дәфтәр

Тылсымлы сүз 4
Соңару 5
Ялгыз кыз 7
Серле авазлар 10
Кайнар дәфтәр 14
Йолдызлы кәшәкәләр 20
Ленин тавы 24
Үткәннәрнең моңлы хатирәсе 27
Минем әбием 29
Көтелмәгән сорау 33
Хыялдагы яшел яз 35
Югалган тынычлык 41

Энесенә ул апа

Айсылу 46
Кашыклар 47
Беренче хат 48
Кечкенә Ринат 50
Миләш нигә ачы? 50
Энесенә ул апа 52
Һәйкәл 54

Имәндә икән чикләвек

Оныгы әбисен ничек кунак итте . . . 56
Йокы чүлмәге 60
Имәндә икән чикләвек! 62
Беренчеләр 64
Иҗат газабы 65
Белсеннәр кемлегемне 66

Рафис Гыйззәтуллин

Г 92 Күтелмәгән сорау: Хикәяләр.— Казан: Татар. кит. нәшр., 1990.— 70 бит.

Г $\frac{\mathbf{4803010200—113}}{\mathbf{М\ 132(03)—90}}$ **170—90**

Издание для детей и юношества

Гиззатуллин Рафис Ахатович

ТРУДНЫЙ ВОПРОС

Рассказы

(на татарском языке)

Редакторы **Т. Нурмөхәммәтов**
Художество редакторы **Ф. Хәсьянова**
Техник редакторы **М. Абитова**
Корректоры **Р. Хәкимова**

ИБ 5696

Җыярга тапшырылды 24.11.89. Басарга кул куелды 11.06.90. Форматы $60 \times 90^1/_{16}$. Типогр. кәгазе № 1. «Балтика» гарнитурасы. Кабарынкы басма. Шартлы басма табагы 4,5. Шартлы буяу-оттиск 5,5. Нәшер-хисап табагы 2,92. Тиражы 15 000 экз. Заказ 3-583. Бәясе 15 тиен.

Татарстан китап нәшрияты. 420111. Казан, Бауман ур., 19.
Татарское книжное издательство. 420111 Казань, ул. Баумана, 19.

Татарстан АССР Нәшрият, полиграфия һәм китап сәүдәсе эшләре дәүләт комитетының Камил Якуб исемендәге полиграфия комбинаты. 420111 Казан, Бауман ур., 19.

15 тиен